


АЗАТ ХАТЫН

1926 ЕЛДА ЧЫГА БАШЛАДЫ

НОЯБРЬ • 1977





Гөлнур Ханова Чаллыга Уфадан килде. Ул хәзер заводның җыю цехы алдынгысы. Ил буйлап таралган КамАЗ машиналарында аның өлеше дә бар.



КамАЗ. БАШ КОНВЕЙР.

Соңгы елларда Чаллы турында, шул кечкенә генә борынгы шәһәрдә салынган ҚамАЗ турында дөньяның күп якларында сөйли башладылар. Монда илнең иң уңган яшьләре җыелды, дөньяның өр-яңа техникасы тупланды. Моңарчы берәү дә күрмәгән темпларда барган төзелеш киң колачлы комплексның тиз арада авыр йөк машиналары җитештерә башлавын тәэмин итте. Бүген күкрәгенә «ҚамАЗ» тамгасы төшерелгән авыр йөк машиналары басулардан икмәк ташуда да, төзелешләргә авыр-авыр панельләр китереп торуда да, завод-фабрикаларның ихтыяҗын канәгатьләндерүдә дә катнашалар. Хәзер безнең урамнарны бу баһадирлардан башка күз алдына китерүе дә кыен. Алар арта, төрләнә бара.

Шушы агым өзелмәсен өчен ҚамАЗның һәр цехында тынгысыз хезмәт кайный. Қомплексның барлык заводлары бердәм тырыша, ә гомум тырышлык бер ноктада — бер конвейер эшендә күренә. Қоллективларның социалистик ярышында иң әһәмиятле пункт булып шул санала: баш конвейерның хәрәкәтенә өзеклек китермәскә!

ҚамАЗ эшчеләре Октябрьның 60 еллыгына унынчы бишьеллыкның ике еллык планын үтәү турында йөкләмә кабул иткәннәр иде. Уңганнарның бөтен тырышлыгы әнә шул изге бурычны тормышка ашыруга юнәлдерелде.

Р. ЯКУПОВ фотолары.

СССР Верховный Советы Президиумының 1977 ел, 27 май Указы белән расланды *

СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАЛАР СОЮЗЫ ГИМНЫ

С. МИХАЛКОВ һәм Г. ЭЛЬ-РЕГИСТАН
текстлары
Әхмәт ИСХАК һәм Нури АРСЛАНОВ
тәрҗемәсе
А. В. АЛЕКСАНДРОВ
музыкасы

Республикаларны туплап нык союзга,
Бөек Русь азат, җиңелмәс ил төзде.
Яшә син, халык теләге тудырган ил,
Бердәм, куәтле Советлар Союзы!

Дан сиңа, дан, безнең азат Ватаныбыз,
Бар халыклар дуслыгы нигезе!
Ленинчыл партия — син халкыбыз көче,
Син илтәсең коммунизмга безне!

Ирек кояшы балкыды давылларда,
Бөек Ленин юл яктыртты көрәштә:
Илне күтәрде хаклыкны дауларга ул,
Бирде рух безгә яуларда һәм эштә.

Дан сиңа, дан, безнең азат Ватаныбыз,
Бар халыклар дуслыгы нигезе!
Ленинчыл партия — син халкыбыз көче,
Син илтәсең коммунизмга безне!

Күрәбез илнең киләчәк көннәрен без
Сүнмәс коммунизмның җиңүләрендә,
Кызыл байрагына данлы илебезнең
Тугры булырбыз без гомер-гомергә!

Дан сиңа, дан, безнең азат Ватаныбыз,
Бар халыклар дуслыгы нигезе!
Ленинчыл партия — син халкыбыз көче,
Син илтәсең коммунизмга безне!

Торжественно. Распевно.
Тантаналы. Сузылыклы.
mf
Со-юз не-ру-ши-мый рес-пуб-лик сво-
Рес-пуб-ли-ка-лар-ны туп-лап нык со-
f mf
бод-ных спло-ти-ла на-ве-ки Ве-ли-ка-я Русь. Да
юз-га, бө-ек Русь а-зат, җи-ңел-мәс ил төз-де. Я-
здрав-ству-ет со-здан-ный во-лей на-ро-дов е-ди-ный, мо-
шә син, ха-лык те-лә-ге ту-дыр-ган ил, бер-дәм, ку-әт-
гу-чий Со-вет-ский Со-юз! Славь-ся, О-
ле Со-вет-лар Со-ю-зы! Дан си-ңа,
f
те-чес-тво на-ше сво-
дан, без-нең а-зат Ва-
cresc...
mf
бод-но-е, друж-бы на-ро-дов на-
та-ны-быз, бар ха-лык-лар дус-лы-
mf cresc...
ff
деж-ный о-плот! Пар-ти-я Ле-ни-на —
гы ни-ге-зе! Ле-нин-чыл пар-ти-я —
cen do ff
си-ла на-род-на-я нас к тор-жест-ву ком-му-
син хал-кы-быз кө-че, син ил-тә-сең ком-му-
Для повторения / Кабатлау өчен — mf
Для окончания / Тамамлау өчен — ff
низ-ма ве-дет! Сквозь-низ-ма ве-дет!
низм-га без-не! И- -низм-га без-не!
rit. ff

* Татарча текст Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1977 ел, 4 август карары белән расланды.

Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!
СССР
АЗАТ ХАТЫН 11
НОЯБРЬ
Иҗтимагый-политик һәм әдәби-нәфис журнал. 1977

© «Азат хатын», 1977 ел.

В. В. НИКОЛАЕВА-ТЕРЕШКОВА,
очучы-космонавт,
Совет хатын-кызлар
комитеты председателе.

ОКТЯБРЬ



Бөек Октябрь социалистик революциясе кешелек җәмгыятенең үсешен тамырыннан үзгәртте. Тарихта беренче буларак, хезмәт халкының эксплуатациягә, социаль һәм милли изүләргә каршы көрәше җиңү белән тәмамланды. Дөньяда беренче социалистик дәүләт барлыкка килде, хезмәт ияләренә тулы хокук бирелде. Бөек Октябрь яңа эпоха — капитализмнан социализмга күчү эпохасын ачты. Социалистик революция тантанасы планетабызда халыкара эшчеләр хәрәкәтенә көч бирде, милли-азатлык көрәшен җәелдерергә яңа мөмкинлекләр күрсәтте. Милли-азатлык хәрәкәте нәтиҗәсендә колониаль система җимерелде, элекке колонияләр урынында йөздән артык бәйсез дәүләт барлыкка килде, аларның күбесе социалистик үрнәктә үсеш алдылар.

Совет иленең алтмыш ел эчендә ирешкән уңышлары безнең күз алдыбызда. Социалистик индустрия һәм авыл хуҗалыгын коллективлаштыру, культура революциясе, милли мәсьәләне дөрес хәл итү Ватаныбызны тарихи кыска вакыт эчендә куәтле социалистик державага әверелдерде. СССРның яңа Конституциясен кабул итү илебезнең социаль үсештә тагын да югарырак баскычка күтәрелүен күрсәтә.

СССР Конституциясе — безнең хокукларыбыз һәм бурычларыбыз хакында. Без, хатын-кызлар, Конституция нигезендә тормышыбызның политик, экономик, социаль һәм культура өлкәләрендә ирләр белән бертигез хокук алдык. Моннан алтмыш ел элек, Совет власте игълан ителүнең беренче көннә-

БЕЗНЕҢ ЮЛ

Бөек Октябрь социалистик революциясенең хезмәт кешесен нинди бөеклеккә күтәрүе турында уйлана башласам, фикерләрем ирексездән үз предприятиебезгә килеп тоташа. Безнең республика кешеләре аяк киеме тегү, аны каеп чигү белән элек-электән шөгыльләнгәннәр. Каймалы чүәкләр, чәмчәле читекләр татар кызларының иң яраткан киеме булган. Кызганычка каршы, элек затлы аяк киеме күп кызларның хыялында гына йөреп калган. Әйбәт күннән тегелгән биек үкчәле ботинкалар да, күз явын алырлык читекләр дә бай хатыннарыннан артмаган. Европа базарларын шаулаткан татар читеге гади халыкның күз нурын, бөтен гомерен суыручы товар саналган. Казан итекчеләре ярымподвал хәлендәге, эш өчен һичнинди шартлары булмаган биналарда теккәннәр. Хезмәт гел кулдан башкарылган. Фабриканың «Поляр» дигән исеме дә булган. Анда нибары 300 ләп оста исәпләнгән, аларның эш көне уникешәр сәгатькә сузылган.

Октябрь исә шушы һөнәргә өр-яңа язмыш алып килә. Егерменче елларда фабрикага «Спартак» дигән яңа исем бирәләр. Цехларда үзгәртеп корулар, кул хезмәтен акрын-акрын машиналарга күчерүләр башлана. Теләк бер, омтылыш бер, максат бер булгач, коллектив җиңү арты җиңүгә ирешә. Әйбәт сыйфатлы аяк киеме җитештерү сизелерлек арта. Фабрикада җәмгыять өчен җаннарын аямый тырышучы квалификацияле эшчеләр гвардиясе тәрбияләнә.

Предприятиенең тышкы күренеше дә танымаслык булып үзгәрә башлый. Кайбер цехлар өчен өр-яңа биналар салына, яшьләрне өйрәтү өчен ФЗӨ мәктәбе ачыла. Утызынчы елларда фабрика елына бер миллион

һәм БЕЗ

«Хатын-кыз һәм социализм» дигән халыкара очрашудагы докладтан (июль, 1977 ел).

рендә үк, хатын-кызларны кимсеткән бөтен законнар юкка чыгарылды, хатын-кызларга җәмгыятьтә һәм гаиләдә ирләр белән тигез хокук бирү турында декретлар кабул ителде. Тарихта беренче буларак, хатын-кызның ана булуы иң әһәмиятле социаль функция итеп каралды, хатын-кызга һөнәр алу, иҗтимагый-политик активлыгын ана булу вазифалары белән бергә алып бару мөмкинлекләре тудырылды. Кыска вакыт эчендә хатын-кызлар укыргаязарга өйрәнделәр, профессиональ әзерлекләрен үстерделәр, җәмгыятебезнең бөтен сфераларында эшләрлек, дәүләт белән идарә итәрлек дәрәҗәгә күтәрелделәр.

Совет хатын-кызлары революциядән күп нәрсә алдылар, һәм алар революциягә бурычлы булып калмадылар. Гражданнар сугышының утлы елларында, беренче бишьеллыкларның удар төзелешләрендә, Бөек Ватан сугышы көннәрендә һәм хәзер — социализмнан коммунизмга күчү вакытында — хатын-кызлар һәрвакыт гомуми эшкә лаеклы өлеш кертәләр.

Безнең илебездә хатын-кыз катнашмаган эш юк диярлек. Соңгы елларда кул хезмәте җиңеләйгәннән-җиңеләя, хатын-кызлар машина төзелеше, химия промышленносте предприятиеләрендә, электроэнергетикада — техник прогрессның алгы сафындагы тармакларда күбрәк эшли башладылар, инженертехник җитәкчеләр арасында да хатын-кызлар күп. Авыл хуҗалыгында эшләүче апалар, сеңелләрнең дә кул хезмәте машина хезмәте белән алыштырыла.

Җитлеккән социалистик җәмгыять өчен акыл хезмәтендә эшләүчеләрнең күп булуы кирәк. Хатын-кызлар арасында югары һәм махсус урта белем алучылар елдан-ел арта бара. Хәзер илдәге югары һәм махсус урта белемле белгечләрнең 59 проценты, экономистларның 60 проценты хатын-кызлар. Мәгариф һәм медицина өлкәсендә хатын-кызлар тагын да күбрәк. Ярты миллионнан артык совет хатын-кызлары промышленность предприятиеләрендә, колхоз һәм совхозларда дәүләт учреждениеләрендә, төзелешләрдә һәм башка урыннарда җитәкче эшләрдә эшлиләр.

Фән өлкәсендә дә хатын-кызларыбыз могҗизалар тудыра. Элеккечә биология, медицинада гына түгел, хатын-кыз галимнәр атом-төш синтезын, космик биологияне өйрәнәләр, математика, физика һәм генетика, радиотехника һәм минералогия кебек катлаулы өлкәләрдә эшлиләр. Югары уку йортларындагы студентларның яртысы хәзер хатын-кызлар.

Совет хатын-кызларының иҗтимагый активлыклары да артканнан-арта. Җирле Советларга соңгы тапкыр миллионнан артык хатын-кыз депутат итеп сайланды, СССР Верховный Советында алар 475 кеше, ягъни, һәр өч депутатның берсе хатын-кыз. Алар закон проектларын тикшерүдә, халык хуҗалыгы планнарын, дәүләт бюджетын кабул итүдә, илебезнең эчке һәм тышкы политикасы мәсьәләләрен хәл итүдә катнашалар. Болардан тыш миллионнарча хатын-кызларыбыз халык арасында партиябез һәм хөкүмәтебез карарларын аңлату буенча зур эш алып баралар.

Социалистик демократия дәүләт төзелеше сферасы белән генә чикләнми, ул иҗтимагый тормышта да чагыла. Мәсәлән, 16 миллионлы Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең дүрттән бер өлешен хатын-кызлар тәшкил итә, комсомоллар сафында яшьләрнең яртысыннан күбесе, профсоюз членнарының яртысы — хатын-кызлар.

Хатын-кызларның иҗтимагый-политик активлыгы аның семьядагы активлыгына да бәйләнгән. Партия һәм хөкүмәтебез семья һәм көнкүреш мәсьәләләренә аеруча игътибар бирә, семья мәнфәгатьләрен махсус законнар нигезендә саклый һәм гаилә бәхете өчен бөтен мөмкинлекләр тудырырга тырыша. Унынчы бишьеллыкта гына да элекке 12 миллион бала янында тагын 2,8 миллион бала бакча һәм яслеләрдә тәрбия алачак. Укучылар өчен озайтылган көн группалары тагы да артачак. Һәр ел саен хөкүмәт күп балалы семьяларга пособие бирү өчен ике миллиард сумга якын акча билгели.

Ана кешенең иң төп вазифасы — бала тәрбияләү, илебезгә лаеклы кешеләр үстерү. Гаиләдә бу бурыч ата белән анага тигез йөкләнә. Ата белән ана балада гражданлык, патриотизм һәм интернационализм хисләре тәрбияли. Яхшы күңеллелек, үзара ярдәмләшү һәм тугрылык кебек бик мөһим сыйфатлар да башлап семьяда тәрбияләнә.

Менә шуның өчен КПСС Үзәк Комитеты һәм Совет хөкүмәте хатын-кызларның гаиләдә тоткан роленә аеруча югары бәя бирә.

Совет властеның беренче елларында ук, дәүләтебезгә нигез салучы бөек Ленин болай дигән иде: «Бер генә дәүләт тә, бер генә демократик закончалык та хатын-кызлар өчен төзелүенең беренче айларында ук Совет власте эшләгәннең яртысын да эшли алмады... һәм без моның белән хаклы рәвештә горурланабыз».

Әйе, горурланабыз. Совет иленең бүгенге казанышлары Бөек Октябрь социалистик революциясенең хатын-кызларга биргән хокуклары нәтиҗәсе дә ул.

---

740 мең пар аяк киеме җитештерерлек куәткә ия була.

«Спартак» берләшмәсенең бүгенге хәлен бәяләү өчен тарихка күз салсаң, аның буеннан-буена партия оешмасының фидакарьлеге күренеп тора. Һәр яңалыкны беренче башлап фабриканың коммунистлары күтәреп чыга. Кайда кыен, кемгә ярдәм кирәк, иң алда алар бара. Предприятиенең «Хезмәт һәм көрәш даны музее»нда беренче җитәкчеләрнең, яңа алымнарны әйдәп баручыларның исемнәре алтын хәреф белән язылган: Н. Алексеев, Н. Сметанин, ветераннар — З. Аипова, Н. Иванова, У. Аипов. Иптәш Аипов башта гади кисүче булган, аннан директор урынбасары итеп куйганнар, соңрак җиңел промышленность министры дәрәҗәсенә күтәрелде. Сания Заһирова гади генә кисүче иде, аңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде. Г. Ситдикова хезмәт юлын җыештыручылыктан башлап җибәргән, соңыннан мастер булган. Аны Татарстан Верховный Советына депутат итеп тә сайладылар.

Предприятие ветераннары беренче бишьеллыклардагы энтузиазм турында, Бөек Ватан сугышы чорында аяк киеме тегүчеләрнең фидакарьлеге турында гаҗәп матур истәлекләр хәтерлиләр. Ир-егетләр сугышка китеп баргач, фабриканың хатын-кызлары бердәм булып яңа, элек гел ирләр генә өйрәнгән һөнәрләр үзләштерергә тотынганнар. Теләк бер булган: «Фронт өчен! Дошманны тизрәк җиңү өчен!» Комбинатта героик хезмәт үрнәге күрсәтүче фронт бригадалары төзелгән. Бу коллективларны Развалова, Владимирова, Мостафина, Терехова, Богаткина кебек уңганнар җитәкләгән.

Спартаклыларның Бөек Ватан сугышы елларындагы тырышлыгын бик кадерле бер бүләк — Дәүләт Оборона Комитеты тарафыннан мәңгегә саклау өчен бирелгән Кызыл Байрак дәлилләп тора. Бу изге байракны алганчы Казан итекчеләре фронтка биш ярым миллион итек тегеп озаталар. Кыен шартларда башкарылган бу хезмәт өчен комбинатның уннарча уңганнары хөкүмәт тарафыннан орден-медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соңгы чор предприятие өчен тагын да авыррак була. Биналар искергән, җиһазлар юлдан чыккан, чимал юк дәрәҗәсендә. Барыннан да авыры — коллективның алтын

куллы осталары яу кырында ятып калган. Әмма комбинат өзлексез алга бара. Сугыштан соңгы унике ел эчендә цехларга гомуми озынлыгы чакрымга якын сузылган конвейерлы җайланма куела, киптергечләр механизмнарга һәм конвейерларга көйләнә, күптөрле машиналар, пресслар кайтарыла.

Моннан соңгы үзгәрешләр КПСС съездлары карарларын тормышка ашыру белән бәйләнгән. Бүгенге көнгә «Спартак» берләшмәсе РСФСРдагы иң күренекле предприятиеләрдән санала. Мондагы аяк киемнәре заманның иң алдынгы җиһазларында, иң алдынгы ысуллар белән җитештерелә. Производствоның аерым фабрикалары, цехлары, филиаллары киләчәктә специальләшәчәк, хезмәт тагын да конкретрак төс алачак.

Эшне фәнни нигезгә куйгач, техника прогрессы, планлаштыру, экономика һәм финанс мөмкинлекләре белән исәпләшү нәтиҗәсендә хезмәт бөтенләй башка юнәлеш алды. Коллектив хезмәт житештерүчәнлеген күтәрү, чималны экономияләү, яңадан-яңа эчке резервларны ачу юлыннан бара.

Администрация һәм идарә аппаратындагы кешеләр санын киметү турыдан-туры эшкә бәйле яна бүлекләр ачарга ярдәм итте.

Соңгы бишьеллыкларда берләшмәнең уңышлары аеруча зур булды. Производствода хезмәт җитештерүчәнлегә егерме тугыз процентка артты.

Яңалыкларга тагын шуны да өстәргә кирәк: соңгы вакытта без ясалма күннән матур-матур ботинкалар, туфлиләр, читекләр тегәргә өйрәндек. Тугызынчы бишьеллык азагында унынчы бишьеллыкны уңышлы башлап җибәрергә безнең бөтен мөмкинлекләр дә бар иде инде.

Бүген спартаклылар, үзара ярыша-ярыша, арада берәү генә дә артка калмасын, дип, тырыша-тырыша КПССның XXV съезды карарларын тормышка ашыра. Алдыбызга съезд куйган төп бурычны — эффектлылыкны арттыру, сыйфатны күтәрү өчен өзлексез эзләнүләр бара. Партком утырышларында, партия һәм профсоюз җыелышларында да төп игътибар шул бурычка юнәлтелә.

Тырышлыкның беренче нәтиҗәләре күренә дә башлады инде. Берләшмә чыгарган аяк киемнәренең кайбер төрләре кибеткә китерелгән көнне үк алынып бетә. Сәүдә оешмалары сорау хатларын яудырып кына торалар, заказлар арта бара. Биш төрле аяк киеменә, унөч модельгә Дәүләт сыйфат билгесе бирелде. Алар арасында БАМ төзүчеләре өчен тегелә торган җылы итекләр дә бар. Без шундый утыз мең пар аяк киеме тегеп озаттык инде.

Сыйфат хакында бик нытып сөйләшергә бөтен мөмкинлекләр бар. Хәзер безнең берләшмәнең төп производствосы комплекслы механикалаштырылган. Җитмеш конвейер агымының гомуми озынлыгы ике чакрымнан артып китә.

Хатын-кызлар — бездә төп көч. Планнарыбыз үтәлешен дә, сыйфатның яхшыруын да алар хәл итә. Уңган кызларыбыз арасында депутатлар, башлангыч партия оешмаларының җитәкчеләре күп. Социалистик Хезмәт Герое Сания Заһирова, КПССның XXV съезды делегаты Г. Федонина, ТАССР Верховный Советы депутаты Л. Новикова, җиңел һәм текстиль промышленносте работниклары профсоюзларының X съезды делегаты Ф. Салахова, Ленин орденлы М. Юзеева кебек эшчеләребезнең исемен ил күләмендә беләләр.

Совет чынбарлыгында аяк киеме тегүчеләрнең культура һәм белем дәрәҗәсе дә бик үсте. Тегүчеләребезнең шактые вузларда, техникумнарда, кичке мәктәпләрдә белем алалар, төрле түгәрәкләргә йөриләр. Алдынгы эшчеләр Октябрь тантанасы уңаеннан күтәренке йөкләмәләр алган иде. Коллективның яртысы бәйрәмгә еллык планнарын үтәп өлгерделәр. Бу эштә партия комитетының, комсомол һәм профсоюз оешмаларының әйдәүче роле бик зур булды.

Ләлә МӘҺДИЕВА,
берләшмәнең партия комитеты секретаре.

ЭШТӘН КУЫЛГАН МАДОННАЛАР

Җан өшеткеч бу хәлләрнең башланып китүенә ике ел тулып узды инде. 1975 елның 14 нче октябрендә Лионга якын гына урнашкан Вийербан шәһәрчегендәге «Обсесьон» исемле тегү фабрикасы хуҗасы предприятиенең ябылачагын игълан итте. Тегүче хатын-кызлар эштән китәргә мәҗбүр иде. Димәк, яңа эш эзләргә кирәк.

Франциядә эшсезләр саны миллионнан артып киткән вакытта, хезмәт урыны табу уен түгел. Вийербанның үзендә генә дә кулларына эш таба алмый интегүчеләр меңнән артык, Лионда андыйлар әллә ничә дистә меңгә тула.

Хуҗа хәлне гади генә итеп аңлатып бирде. Фабриканың рентабельлеген саклау кыен. Ул хәзер хезмәт җитештерүчәнлеге нык ус-



Радиотапшырулардан ишетеп тә, газета-журналлардан укып та без капиталистик җәмгыятьтә кешегә эш җитмәвен белеп тора идек инде. Франциянең Вийербан шәһәрендәге хәлләр исә минә аеруча сәерсендерде. Бу хакта мин «Комсомольская правда»дан укыдым. «Обсесьон» кызлары нәкъ безнең эшне башкаручылар, хатын-кыз күлмәге тегүчеләр икән бит.

Мин үзем Казанда 1 нче фабриканың 2 нче цехында эшлим. Егерме бер ел буе күлмәкләр тегәм. Күзләремне йомып, бер генә мизгелгә үземне Иреннар, Полетталар хәленә куеп карасам, йөрәгем «жу-у» итеп китә. Эшсез кал имеш. Бу бит кулсыз, аяксыз, хәрәкәтсез калу белән бер. Алай гына да түгел, рухыңның сынуы, киләчәккә өметең өзелү. Монысы тагын да куркыныч нәрсә. Яшәүнең мәгънәсе бетә, кешеләргә кирәгең калмый, дигән сүз. Шул якларын уйласаң, үз язмышым һәм илебездәге үземдәй миллионнарча хезмәттәшләрем өчен шатланып бетә алмыйм. Чөнки бүген француз хатыннары кичерә торган бәхетсезлек, эшсез калу, ягъни җәмгыятеңә кирәгең бетү кебек куркыныч язмыш безнең илдә бөтенләй юк, булуы да мөмкин түгел.

кән зур предприятиеләр белән конкуренциягә керә алмый башлаган, җиңелгән.

Юк, хуҗа ялган сөйләми, дөресен әйтә ул. Зур монополияләрнең товарына каршы тора алмастай продукция чыгарып ятуның аңа, чыннан да, һичнинди файдасы юк. Ә фабриканың ике йөз илле биш тегүчесе бу хакта уйламый. Аларның үз кайгысы баштан ашкан: гаиләдә акча көтәләр.

Хуҗа фабрикадагы телефон, электр, җылыту системаларын өзгән көнне хатын-кызлар бер карарга килделәр.

— Фабрика яңадан эшли башлаганчы, без бу бинадан чыгып китмибез! — диделәр алар.

Без «Обсесьон» эшчеләре белән очрашырга барганчы ук Франция газеталарының берсендә бу вакыйгага багышланган мәкалә чыккан иде. Автор: «Обсесьон» тегүчеләре предприятиедән куып чыгарылырмы, юкмы?» — дигән сорау куйган. Мәкаләдә мондый мәгълүматлар язылган.

«...Кичә «Обсесьон» фабрикасы хуҗасының адвокаты кичекмәстән каралырга тиешле эшләрне тикшерүче судьядан предприятие цехларын бушатуны, җиһазларны һәм складтагы әйберләрне тиз арада күчереп бетерүне таләп итте.

Гомуми хезмәт конфедерациясенең күлмәк тегү промышленносте хезмәткәрләре профсоюзы вәкиле Ролан Сгорбини әфәнде исә үзенең чыгышында болай диде. «Тегүчеләрнең унҗиде ай буе фабрикадан чыкмый ятулары ничек тә эш урынын саклап калырга тырышудан килә. Предприятиедәге җиһазларны сатып бетерү фабрика хуҗасының теләген тормышка ашырачак. Гаделлекме бу?..»

«Обсесьон»га бару юлында без Лион шәһәренең гаҗәеп матур архитектурага нигезләнгән күркәм урамнарыннан уздык. Тарихы ике мең елга сузылган бу борынгы шәһәрнең тар тыкрыкларында тукучыларның күптәнге тәвәккәллеге искә төшә. Үткән гасыр башында ук алар Кызыл байрак күтәреп урамнарга чыгалар, деспотизмга каршы күтәреләләр. Икенче бөтендөнья сугышы елларында, гитлерчылар оккупациясе шартларында да, шәһәрнең бу районы үзенең мөстәкыйльлеген саклап калган.

«Обсесьон»ның тимер капкасына: «Фабрикада — хезмәт иясе»,— дигән язу эленгән. Департаментның Коммунистик яшьләр федерациясе секретаре Жаки капка баганасындагы кнопкага басты.

Безне инде көтәләр иде. Барысы турында да бәйнә-бәйнә сөйләргә тотындылар.

— Без хәзер 255 кешедән утызау гына калдык инде. Шул утыз кеше сменаларга бүленә. Бишәр-алтышар кеше калып, фабриканы саклыйбыз. Кунарга да туры килә.

— Куркыныч түгелме соң?

— Башта шомлырак иде.— Жаки мине беренче итеп таныштырган Ирен Женикен куркуын яшерергә дә теләми.— Беренче айларда ниндидер егетләр төрле провокацияләр ясап маташтылар. Төнлә куркыныч бит. Күз дә йома алмый идек. Хәзер рәхәтләнеп йоклыйбыз! — Ул почмактагы урын-җиргә ишарәләде.

Һәр атнаның чәршәмбе көнендә забастовкачыларның барысы бергә җыела. Өлге кисү өстәлендә төшке ашны бергәләп ашыйлар. Гаҗәеп табын, сәер мәҗлес иде бу. Тыныч. Ашыгучылар юк. Без әллә кайчангы танышлар кебек гәп корабыз. Табындагы кешеләрнең якынлыгын арттырырга тагын бер сәбәп — хатын-кызларның кулыннан-кулына күчеп йөрүче бер бала бар монда. Иркәләүләре ошап китсә, көлә ул, берәрсе җайсызрак тотса, тынычсызлана башлый. Ирен кулына килеп кергәч, сабыйның йөзе бөтенләй балкып куйды.

— Әни-әни шул инде ул! — диде өлкән яшьтәге бер хатын.— Әтиең дә монда бит, ник аңа бармыйсың? — Ул, елмаеп, читтә торган аксыл чәчле ир-егеткә таба ымлады.— Сериль исемле бу бала шушы фабрикада туды. Хәзер менә әнисе көн-төн монда булгач, ул да фабрикада яшәргә мәҗбүр. Әнисе — партия ячейкасы секретаре. Бу хәлләр башланганда, Ирен бердәнбер коммунист иде. Хәзер алар унберәү!

— Нишләп «алар» дип сөйлисез? Сез бу фабрика кешесе түгелмени?

— Түгел шул. Мин күршедәге «Боя» фабрикасыннан. Без ирләр киеме тегәбез.

Сүзгә оста бу хатын күрше предприятиенең профсоюз оешмасы тарафыннан махсус җибәрелгән икән. Хәлләре ничек? Ярдәм кирәкмиме? Күршеләр барын да тикшереп торалар. Чөнки «Обсесьон»дагы күңелсез вакыйгалар Франциянең күп кенә башка предприятиеләренә дә килүе бик мөмкин. «Боя»-да моннан унбиш ел элек мең кеше эшләгән, хәзер алар дүрт йөз генә. 1966 елда Франциянең тегү, текстиль, күн промышленностена миллионнан артык кеше хезмәт күрсәткән. Аларның күпчелеге хатын-кызлар булган, әлбәттә. Хәзер бу тармакта алты йөз ун мең кеше калган. Илдәге эш эзләүчеләрнең алтмыш ике проценты — хатын-кызлар.

Матур ил ул Франция! Луврдагы, Версальдагы картина галереяларында нинди гүзәл хатын-кыз образлары тезелгән! Бөек рәссамнар берсеннән-берсе остарак итеп мадонналарның елмаюлы йөзләрен сурәтләргә тырышканнар. Баласын кочаклап эш көтеп утыручы Иреннар, Полетталар язмышы турында уйланганда исә ул елмаюларда әрнү, ачыргалану, кимсетелү генә тоярга мөмкин.

В. МАКАРОВ,
«Комсомольская правда» газетасыннан
кыскартып алынды.



Кешенең хезмәткә тулы хокукы безнең илнең Төп Законына алтын хәрефләр белән язылган һәм бу хокуктан һәркем тулысынча файдалана. Моңа мин тирәннән ышанып, үз предприятиебез тормышын мисалга алып әйтәм. Эшлә генә, рәхәтлән, кулларың гына талмасын!

Мин әле тегү фабрикасы хакында гына түгел, башка завод-фабрикалар турында да әйтә алам. Бу үзем яраткан эшкә тап булганчы берничә ел икмәк заводында, берничә ел авиация заводында эшләгән идем. Аларда да хезмәт кешесен зурлауларын, хезмәтеңә күрә хөрмәт күрсәтүләрен тоеп тордым. Соңыннан әни һөнәре кызыктырды. Ул әлеге тегү фабрикасында эшли иде. Үзе янына мине дә тартты. Аның мондагы хезмәт стажы утыз елга тула, хәзер пенсиядә инде. Мин аннан өйрәнеп алган осталыкны һаман чарлыйм әле.

Хәер, осталыкка өнидән генә өйрәндем дип әйтү дөрес тә булмас. Бездә яшьләрне бик теләп кабул итәләр һәм өлкәннәр аларны үз канат асларына алырга гына тора. Соңгы елларда осталык хәрәкәте бигрәк тә киң таралды. Үзең өйрәткән яшь кешенең беренче тапкыр эш хакы алып шатлануы, беренче тапкыр норма тутыруы, аннары сине узып та китүе күңелне берсеннән-берсе ныграк дулкынландыра торган куанычлар бит.

Соңгы вакытта мин бу турыда аеруча күп уйлана башладым. Сәбәбе ни дисезме? Бәлки шулай эшли-эшли бераз олыгая төшүемдер дә. Икенче яктан, елы бик истәлекле бит. Октябрьның 60 еллыгы җитте. Илдә яңа Конституция кабул ителде. Бу куанычлы хәлләрне дәшми-тынмый гына кичереп йөрисең-йөрисең дә бер уйланмасаң, бер уйлап куясың: рәхәт бит яшәү, матур бит көннәребез! Тормышның кай ягына күз салма — җанны шатлык били.

Хезмәтем турында сөйләгән идем инде. Икенче шатлыгым — гаиләм. Ирем, улым, әнием бар. Һәрберсе күңелемә бетмәс-төкәнмәс куаныч өстәп яши. Ирем Якуб та хезмәтне бик ярата. Бергә яши башлавыбызга унҗиде ел, аның бер генә вакытта да эштән авырсынганын, зарланганын ишеткәнем юк. Ул — слесарь. Егерме өч елдан бирле бер мастерда эшли. Үзенә квартира да тәкъдим иткәннәр иде. Чыкмадык, кире кактык. Үз йортыбыз белән торабыз без. Йорт янында бакчабыз да бар. Улыбыз Рәис быел тугызынчы класста укый башлады. Җәен ул да әтисе янында эшләп йөрде. Хәйраннарга калдык. Йөз сумга якын акча тоттырып җибәргәннәр үзенә. Фотография белән «җенләнгән» чагы. Аппараты бар инде. Зурайткычлар, объективлар алам, дип йөри.

Мин үзем ялларымны сәяхәт кылып үткәрергә яратам. Шул кадәр дә зур илдә яшәп, аның кай ягында ниләр барын күрми чыдап булмый. Путевка бәясенең күп өлешен фабрика түли. Үткәнендә Украинага барган идем. Быел Балтик буендагы Совет республикаларын йөреп чыктым.

Ял итеп кайткач, тагын да әйбәтрәк эшлисе килә. Мин — өченче разрядлы тегүче. Разрядны да күтәрергә кирәктер, мөгаен. Туры килгәндә, мин иң югары разряд эшләрен дә үти алам үзе. Бер тырышып тотынсам, разрядны үстереп куюы зыян итмәс. Дөрес, фабрикада эшемне яраталар. Мин ел башында норманы 120 процентка үтәп барырга йөкләмә алган идем, әлегә 130—140 проценттан ким үтәгәнем юк. «Почет билгесе» орденым да бар, «Коммунистик хезмәт ударнигы» дигән исем дә бирделәр — ни йөз белән артта сөйрәлмәк кирәк?!

Әнә бит ул безнең дөнья нинди: нәрсә турында гына сөйли башласаң да, шул бер нәрсәгә, эшкә, хезмәт урыныңа, шундагы мәшәкатьләргә, алга куелган максатларга барып чыгасың. Инде көннәрдән бер көнне шул эшеңнән мәхрүм итсәләр, бөтен дөньяң кара төнгә әйләнә, әлбәттә. Полетталар, Иреннар хәлен бик яхшы аңлыйм. Җирдә мондый тигезсезлекләр булмавын телим.

Ләбибә САДРИЕВА,
1 нче фабрика тегүчесе.

Казан.

Элегрәк заманда бу яктан пар ат чаптырып киткән агайлар да Казанга атна буена килгәннәр. Арык атлы крестьяннарга андый сәяхәт тәтемәгән. Тукай яшәгән мәшһүр калаяы ул ишетеп кенә белгән. Республикабыз башкаласыннан иң ерак саналган, элекке Самара губернасына караган бүгенге Баулы районының без сөйләячәк Исергәп, Шалты авыллары хәзер үзәккә асфальт юллар белән тоташкан. Аэропорт, Юлай белән татар Канкайның кем икәннәрен таныган, алпавыт җирләрен крестьяннарга өләшергә теләгәннәрен белгән ул. Шуның өчен алу әле дәвам иткән. Бирегә Самарадан коралды сакчылар чакыртылган. «Бу җир безнеке», дип авыз ачучыларны камчы белән кыйнаганнар, ә фетнәчеләрне Себергә озатканнар.

Үткән заманның ачы хатирәләрен искә төшерүче тагын бер алан бар әле нәргә багып яки ишетеп кенә түгел, үзем дә хәтерлим әле: һәр ике яктагы төтен сузып утырган салам шәлле, бәләкәч өйләр, читән капкалар урынына әнә нинди биек йортлар калыккан. Авыл уртасындагы авыл Советы бинаалары өстендә кызыл флаглар җилферди. Исергәптәге клуб хезмәтен үтәгән Миңнулла бай кладовое урынында 300 урынлы ике катлы таш культура йорты балкып утыра. лән «җиде» арасында күпер чыкмасыннар... Аларга да күз-колак булу кирәк. Ә яшьләр үз эшләре белән мәшгульләр. Бер-берсенә концертлар куярга баралар, сабан туйларында бер көнне Ыкның көнбатышында — Урал итәгендә көрәшсәләр, икенче көнне көнчыгышында — «Әхмәди тугае» буенда биешәләр. Һәр ике як авыллар да туганлашып беткәннәр. Әле күптән түгел генә «Урал»ның уңган



КҮРШЕЛӘР



тимер юл, автобуслар араны тагын да якынайта. Әйе, авыллар-калалар арасында аралар кыскарды, аермалар кимеде хәзер. Ә кайчандыр...

— Кайчандыр Ык буендагы бу як авылларының хәле бигрәк мөшкел иде,— дип сөйлиләр бабайлар.— Җир җан башына дисәтинәләп түгел, аршинлап кыяка бүленгәндер. Җитмәсә, әле Ык та кысрыклаган бичаракайларны. Исергәп мәктәбендә тарих укытучысы мәгариф отличнигы Гали ага Шагалиев аларның сүзен документлап раслый. Екатерина II патшалык иткән чорда булган бу хәл. Язгы ташу вакытында Ык юнәлешен үзгәрткән дә Уфа губернасына кергән Өязтамак крестьяннарының ярты болыны Исергәп авылы ягында калган. «Аллаһы тәгалә рәхмәте белән инде безгә бу печәнлек», дигәннәр Ыкның бу ягындагылар. «Сезнең дәхелегез юк ул болында», дигәннәр Ыкның икенче ягындагылар. Сүздән сүз, кулдан кул киткән. Сәнәкләр, имән күсәкләре күтәрелгән. Рус алпавыты Зиновьев татарлар белән башкортлар арасында купкан бу низагны үз файдасына борып, әлеге «Әхмәди тугае»н үз имениесенә кушкан. Күптән түгел шаулап узган Пугачев восстаниесеннән коты алынган патша власте яклаган аны. Чөнки Пугачев явына кушылган башкорт монда. Ызанга ызан терәлеп торган бер колач җирләрен Исергәп крестьяннары үзара бүлешә алмый даулашканнар. Колхозның терлекләре җәйли торган «Даулы ялан» болыны әнә шул үткәннәрнең шаһиты түгелмени!

Бөек революция җиңгәннән соң бирегә эшне арада татулык урнаштырудан, яшь буынны тәрбияләүдән башлаганнар. Боларны раслаучы документлар архивта саклана. 1919 нчы елның 18 ноябрендә, Исергәп авылы яшьләренең гомуми җыелышында, Баулы волостенда беренче тапкыр комсомол ячейкасы оештыру турында карар кабул ителә. Ә 20 нче елның 14 декабрендә үткәрелгән ячейка җыелышы карарында шундый юллар бар: «...1. Түгәрәкләрдә актив катнашуларын, красноармеецларга иганә җыюда һәм кызыл өмәләрдә нык эшләүләрен искә алып, Рамазанов И., Лотфуллин М., Идрисов Г. һ. б. иптәшләрне РКСМ сафына алырга. 2. Клуб итеп Миңнулла байның таш кладовоен билгеләргә. 3. Башкорт белән Әтәмби як малайларының сугышларын катгый тыярга...»

— Әгәр дә моннан 50—60 еллап элек кенә Өязтамактан яки Исергәптән чыгып киткән берәр агайны кайтарып Ык ярына бастырсаң, танымас иде ул туган якларын, — ди тарихчы Гали ага. — Элекке рәсем-

Заманалар яңа әздән барса да сулар элеккечә ага. Административ картада Ык һаман да элеккечә Татарстанны Башкортстаннан аеручы зәңгәр җеп булып сузылган. Үзәге Исергәп авылы булган «Урал» колхозы аның көнбатышында, Ермәкәй районының Өязтамак, Карат авылларын берләштергән Тельман исемендәге колхозы көнчыгышында ята. «Дөньяда иң озын күпер кайда дисәгез, монда ул», диләр алар шаяртып. Ыкны кичкәндә вакыт бу якта өч кенә булса, чыкканда инде алтынчы киткән булыр. (Башкортстанда вакыт Татарстанга караганда ике сәгатькә алга йөргәнен искәрик). Кайчандыр ызгыш-талаш мәйданы булган «Әхмәди тугае» өчен кан-яшь түгешүләр инде күптән онытылган. Аралашып, дуслашып, туганлашып яшиләр ураллылар белән тельманлылар. Председательләре Җәмит Зыяров белән Мәүлетҗан Гомәровлар хуҗалык эшләре буенча киңәшсәләр (чәчүгә кайчан чыгарга да, уракка кайчан төшәргә), комиссарлары Фәрит Хәмитов белән Мәркәз Хәмидуллиннарны идеологик мәсьәләләр бәйли: халык арасында алып барыла торган агитмасса эшләре уртак, лекторлар алмашалар, алдынгы тәҗрибәләрне уртаклашалар. Кайберәүләр ике арада узган әлеге сәгать поясын файдаланып, «үнбер» бе- кызы Сәкинәне «Тельман» егете Гамир пар ат белән алып киткән. «Тельман» кызы Гөлҗиһанны «Урал» егете Тимерҗан бу якка «Волга» белән алып чыккан. Һәр ике якта да кода-кодагыйлар чөкердәшә.

— Шуны да исегезгә төшерим әле, — ди тарихчы Гали ага, — Исергәп яшьләре хәзер күрше Башкортстанга гына түгел, республика буйлап таралганнар. Яшьләр үсәләр, илләр киңәләр. Ә бит революциягә чаклы бездә адресны да ике генә кеше яза белгән. Колакчын Мәхмүт белән писарь Гыймай булган алар. Кушаматлары белән әйтүемнең сәбәбе шул, берсе күп күргән, күп ишеткәнгә колакчын исемен алса, икенчесе хәрефләрне оста ялгаганга писарь исемен алган. Ә хәзер...

Монысына районның алдынгы мәктәпләреннән саналган Исергәп урта мәктәбе үзе җавап бирә. Мәктәп директоры, Татарстанның атказанган укытучысы Әүхәди Зыяров белән укыту бүлеге мөдире, мәгариф отличнигы Галия Хәлимова иптәшләрнең горурланыр хаклары бар. Колхоз председателе Җәмит Зыяровтан алып бөтен идарә әгъзалары, барлык колхоз белгечләре, авыл Советы хезмәткәрләре һәм укытучыларның күпчелеге шушы мәктәпне тәмамлаган кешеләр. Башта әйткәнебезчә, Исергәп яшьләре бу якларда

гына түгел, бөтен ил буйлап таралганнар. ВЛКСМның Баулы райкомы секретаре Наил Шагалиев шушы авыл егете. Океаннарны иңләгән диңгезчеязучы Миргазыян Юнысов шушы авылда үскән. АзияАфрика илләрендә дәүләтебезнең сәүдә вәкиле сыйфатында экономик киңәшче булып эшләүче Вахит Юнысов та олы юлга шушы мәктәптән атлап чыккан. Ә 24 яшьлек коммунист, колхозның алдынгы тракторчысы, читтән торып механиклыкка укучы уңган Гөлсылу Хөсәеновны бөтен республика белә. Ул — Татарстан Верховный Советы депутаты.

Бөгелмәдән алып Баулыга сузылган, Баулыдан Исергәптә тармакланган асфальт юл Оренбург трактына алып чыга. Бу якка килгән язучылар, сәнгать әһелләре, журналистлар район читендәге Шалты авылына керми калмыйлар. Моңлы, җырлы Ыкның башы моннан 40 чакрым гына. Назлы Кандыз елгасы Ыкка биредә кушыла. Шалты капкасын чыгуга Оренбург өлкәсе башлана.

Башлап шуны әйтик, күп хуҗалыклы бердәнбер Шалты авылыннан торган Ленин исемендәге колхоз быел мул уңыш өчен районара ярышта җиңеп чыкты. Былтыр һәр гектардан 247 шәр центнер бәрәңге алып, еллык заданиене 250 процентка үтәгәне өчен КПСС өлкә комитетының һәм Министрлар Советының күчмә Кызыл байрагын алган. Ул аны быел да ычкындырырга теләми.

— Һәр гектардан 17 шәр центнер уңыш алуыбызның сере нәрсәдә! (Мин бу сорауны колхоз председателе, орденнар кавалеры Газиз Ганиев һәм партком секретаре, Татарстанның атказанган агрономы Вахит Хөснетдинов иптәшләргә бирәм).

— Механизаторларыбыз, игенчеләребез уңганнар, — диләр алар тыйнак кына, — фәнгә, алдынгы тәҗрибәгә таянып эшлибез. Чәчүгә вакытында чыктык, вакытында җыеп алдык. Шуның өстәвенә янәшәдә генә — Оренбург өлкәсенең иң атаклы колхозы. Договорлар белән беркетмәсәк тә, узара ярыш бара.

Гадәти җавап, дөрес җавап. Шулай да бу сорауның сере шунда иде: Шалты табигый шартлары белән Татарстанның башка авылларыннан кискен аерыла. Колхоз территориясенә җитәрәк 20 километр кала моннан 25—30 еллар элек утыртылган посадкалардан башка агач төсе күрмисең. Урманнарга мохтаҗ ул. Ике яклап аккан сулар язын ташып басуларны ашыйлар. Авылга килгәч тә үзеңне башка республикага аяк баскандай тоясың. Урамнары салулы. Берничә өлкәне бәйләгән олы юл шуның аша уза. Барлык йортларның да тәрәзәләре капкачлы, чөнки биредән Оренбург аша Казахстан далаларыннан купкан өермәләр полосасы уза. Андый чакларда йөзәрләгән гектар чәчүлек җирләрен калын тузан каплый. Узган ел да монда кукурузны ике мәртәбә чәчәргә туры килгән. Ә җәйләрен ул яктан искән кайнар җил арыш басуларын көйдерә. Шул сәбәпләр аркасындадыр, бу колхоз озак еллар районның арттагы хуҗалыкларыннан саналып килгән. Ә менә соңгы ике бишьеллык арасында, җитәкчеләрнең эшне оештыра белүе аркасында, ул тамырыннан үзгәрде. Хөкүмәтебезнең мелиорация эшләрен җәелдерергә кушкан карары нигезендә Кандыз буендагы ерымнар бульдозерлар белән тигезләнгән. Кырларны ашап килгән чокырлар эченә читәннәр үрелгән. Көнкүрешен яхшырткач, халык та тырышып эшли.

— Бар иде кайчандыр салам ягып ипи салган, аш пешергән чаклар, — ди колхозның озак еллар бригадир, ферма мөдире булып эшләгән хөрмәтле пенсионеры Зәкия апа Гәрәева, — хәзер күмер ягабыз, газ кабызабыз. Белгечләребезне авылда калдырып, тырышып эшләтү өчен әнә нинди шәп йортлар салып бирде колхоз. Агроном Әмир, бригадир Дамир Шәйдуллиннар өчәр бүлмәле әзер йортларда гына яшиләр. Әнә Кандыз аръягындагы Абдрахманны күрәсезме! Ырынбурга кергән бер бай авыл ул. Хәзер мин күр дә син күр, шуларны узып бара Шалты.

Председатель мактаган Абдуллин районның Калинин исемендәге колхоз үзәге икән Абдрахман авылы. Ә безнең максат Баулының өч өлкә белән чиктәш авылларының, элек җир-су өчен сугышып яшәгән фаҗигале үткәннәренә борылып, бүгенге якты, тату тормышлары белән танышу. Шуны искә алып, әлеге авылга да кереп чыгабыз. Һәр авылның үз тарихчысы була. Колхоз оешканнан бирле агроном булып эшләгән бакчачы Котдус абзый Кәримов яши биредә. Аның бабаларыннан ишеткәнне рәсми материаллар белән дөресләткән язмалары бар. Ул сәхифәләргә караганда, Абдрахман урынында элек Николькино авылы утырган. Ачның ачуы яман дигәндәй, бер тотам кырлә, бер җыем печән өчен җанын фида кылган фәкыйрь мужиклар бер-берсенә ут төртешүгә кадәр барып җиткәннәр. Николькиноның Шалтыдан ун чакрымга ары күчеп утыруының сәбәбе шул. Архивка теркәлгән дата буенча бирегә 1833 нче елны Пензадан Абдрахман атлы кеше үзе белән унбер гаилә алып килгән. Менә ни өчен бу авыл кеше исеме белән атала да, менә ни өчен биредә мишәрчә сөйләшәләр икән. Абдрахман тау итәгендә — ышыкта утыра. Дала җилләре, өермәләр сугылмый аңа. Шуңа күрә ул элек-электән куәтле, нык колхоз булып исәпләнгән. Күршесе булган Шалтыдагы хуҗалыкка ярдәме күп тигән аның.

— Дустың үзеңнән яхшы булсын, — дигәннәр борынгылар, — ди бу яктагы партком секретаре иптәш Хөснетдинов. — Ә без алар белән дуслар. Аларга тиңләшергә тырышып, алар белән киңәшеп күтәреләбез.

— Шалтыларның да үрнәк алыр яклары бар, — ди теге яктагы партком секретаре орденлы Рәис Кәримов, — кукурузны әйбәт игәләр алар. Тулысынча диярлек механикалаштырылган сыерлар абзары башта аларда салынды. Шуннан күрмәкче, без дә менә дигән терлек биналары төзи башладык. Алар хатын-кыз кадрларны үстерүгә игътибар бирәләр. Ферма мөдире булып элекке савымчы, читтән торып институт тәмамлаган Дамирә Мөхәммәтҗанова эшли. Зоотехниклары үзегенә ни тора. Район Советы депутаты Мәхтүмә Халәпова безнең әле солдат шинелен генә салган яшь зоотехнигыбыз Рәшит Низамовка олы үрнәк.

Һәр ике якның инженерлары үзара машина частьлары алмаша. Кызу чәчү өстендә абдрахманлылар шалтыларга баллоннар, сабан төрәннәре биреп торганнар. Шалтылылар аларның трактор моторларын ремонтлаганнар. Эштән соң бергәләп ял итәләр, бәйрәмнәрдә йөрешәләр. Әле күптән түгел генә Шалты культура йорты үзешчәннәре Абдрахман клубында Шаһгалинең «Таң атканда» спектаклен куеп киткәннәр. Баулыга килгән татар язучылары Абдрахман халкы белән очрашмый китмиләр.

— Шулай булмыйни, — ди Калинин исемендәге колхоз председателе Сукут Фәтхуллин, — Татарстан Язучылар союзы секретаре булып Абдрахман үстергән язучы Мөсәгыйть Хәбибуллин утыра ич. Казан радиосының әдәби тапшырулар буенча баш редакторы Рим Кәримов та безнең егет.

Ленин исемендәге колхоз председателе Газиз абыйның да җавабы әзер:

— Сездә тусалар да безнең Казан университетында укып кеше булганнар алар, — ди, елмаеп.

— Шаяруга китсә, шуны да әйтик, — диләр Абдрахманда, — Шалты телевидение аша үз Казанын карый алмый әле, ә без карыйбыз.

— Быел безнең якта да ретрансляция вышкасы сафка баса, ул чакта без Мәскәү, Уфа, Казаннан тыш, дүртенче канал итеп сез карый алмаган үзебезнең Оренбургны да тотачакбыз, — диләр Шалтыда.

Туганлык, дуслык чикләрне белми. Барысы да уртак: уңышлар да, шатлыклар да. Баулылар, Ермәкәйлеләр, Абдуллинлылар Бөек Октябрьның юбилей тантанасын бәйрәм иткән бу көннәрдә үзләренең үткән гыйбрәтле язмышларын тагын бер кат искә төшерәләр дә иркен сулап куялар: нинди тормышта яши идек тә, кем генә идек соң без. Ә хәзер нинди шәп тормыш итәбез дә, менә кемнәр булдык без!!!

Диләрә ЗӨБӘЕРОВА,
махсус корреспондентыбыз.

ОКТЯБРЬ 1917—1977

КОМИССАР

Исәннәр аны яшәүнең тәмен белер өчен искә алсыннар...
Лидия СӘЙФУЛЛИНА.

Неваның армас дулкыннары гранит ярны тырышып-тырышып юалар, җай гына үтеп-сүтеп торган пассажир катерларын йомшак кына тирбәтеп алырга да өлгерәләр. Көне буе архивта бил талдырып, күз ялыктырып утырганнан соң шуларга карап ашыкмый гына яр буйлап уйланып баруы рәхәт.

Тик уйлар әле генә архивта алган тәэсирләрдән тиз генә аерылмый. Дулкыннар шавы да тора-бара Идел дулкыннары тавышы булып ишетелә башлый. Бу юлы мин архивта Идел хәрби флотилиясенә кагылган документлар белән танышам. Киләсе елның сентябрендә Казанны аклардан азат итүгә алтмыш ел тула. Бу да зур вакыйга, олы бәйрәм булыр, чөнки Казанны коткару ул, Владимир Ильич Ленин сүзләре белән әйтсәк, Октябрь революциясен коткарып калуга тиң иде. Менә шушы бик мөһим җиңүдә Идел хәрби флотилиясенең роле ифрат зур булган.

Казан тарихының бу күренекле сәхифәсе анда күп кенә мәшһүр кешеләрнең катнашуы белән дә истәлекле. Азин һәм Чапаев, Вацетис һәм Тухачевский... Идел флотилиясе документларында да күңелгә якын исемнәр еш очрый. Николай Маркин, Всеволод Вишневский, Лариса Рейснер...

Лариса Рейснер. Кем әле ул? Кинәт сорасалар, аптырабрак та калырсың, Такташчарак әйтсәк, таныш та, таныш түгел дә кебек шикелле. Әмма барыбер якын исем, һәм бер нәрсә шиксез: бу исем Бөек Октябрь революциясе белән аерылгысыз бәйләнгән.

Шунда күз алдына В. Вишневскийның үлемсез «Оптимистик трагедия»се килеп баса. Беренче планда, әлбәттә, революция сагына күтәрелгән матросларны каһарманлыкларга рухландыручы батыр һәм чибәр хатын — комиссар. Бу образны драматург Лариса Рейснердан алып язган. Әмма Рейснер хакында сөйләүче чын документ, истәлекләргә мөрәҗәгать итсәк тә, күңелдә барыбер нәкъ менә шундый кеше төсмерләнер иде: революциягә мәңге тугрылыклы, аны саклау өчен утка да, суга да керергә әзер торган батыр йөрәкле, ялкынлы сүзле, үткен каләмле комиссар, шагыйрә күңелле, кешелекле, чибәр һәм ягымлы хатын, тынгысыз журналист.

Хәзер шул документларга мөрәҗәгать итеп, башта Татарстан, Казан турында соңгы елларда чыккан кайбер тарихи китапларга күз салыйк. Ни мәгълүм соң безгә аның турында? Менә профессор М. К. Мөхәррәмовның «Татарстанда гражданнар сугышы» дигән китабыннан берничә юл: «Бишенче армиянең разведка комиссары Лариса Рейснер болай дип язды: «...Бүгенге хәлне барысы да менә болай аңладылар: тагын бер адым артка чигенү «аларга» Нижнийга чаклы Иделгә һәм Мәскәүгә юлны ачачак. Чигенү ул — чехлар Мәскәүдә һәм Нижнийда дигән сүз. Свияжскийны һәм күперне бирмәү — бу Кызыл Армия Казанны кире ала дигән сүз.



Әйе, Лариса Рейснер яңа гына оешып килгән Кызыл флотның һәм Кызыл Армиянең беренче комиссарларыннан иде. Казанга — революция язмышы хәл ителгән ут һәм үлем төбәгенә дә ул очраклы килеп чыккан яисә ничарадан бичара калган кеше түгел иде. Петербургта, алдынгы карашлы профессор гаиләсендә үсеп, уналты яшендә азатлык, көрәш рухы ярылып яткан шигырьләр язган, унтугыз яшендә хөкүмәтне, яшәп килгән тәртипләрне тәнкыйть иткән «Рудин» исемле журналның редакторы булып, анда усал-усал фельетоннар бастырган Ларисаның, Октябрь кораллы восстаниесе алдыннан революцион матрослар белән аралашып, 1917 елның тарихи көннәрендә алар белән бер сафта Кышкы сарайны штурмлауда катнашкан Ларисаның революциянең киләчәге хәл ителергә тиешле Идел буена, ут эченә юл тотуы очраклы түгел иде, әлбәттә. Ленин чакыруына кушылып, Идел буенда баш калкыткан фетнәләрне бастырырга Петроград эшчеләре, матрослар беренчеләрдән булып күтәрелде. Нева дулкыннары Иделгә ашыккан миноносецларны да хәерле юл теләп озатып калды. Идел, Кама, Каспийда зур батырлыклар күрсәткән ул судноларда Лариса да күп тапкырлар ак флотилия өстенә ябырылуда катнаша.

КАЗАНДА ОКТЯБРЬ

Октябрь вакыйгалары Казан гарнизонында башланып китә. 15 нче октябрь көнне гарнизонда булган митингта һәм демонстрациядә 40 мең кеше катнаша. Анда катнашучылар бердәм рәвештә властьны Советлар кулына тапшыруны таләп итеп, резолюция һәм Ленинга котлау хаты кабул итәләр. Бу хәл хәрби округ командованиесенең гарнизон өстеннән власте югалганлыгын күрсәтә. Командование авантюризм юлына басып, большевикларның хәрби җитәкчеләре булган Карл Грасисны һәм Николай Ершовны кулга алырга, большевикларның таянычы булган артиллерия бригадасын коралсызландырырга боерык бирә. Грасис кулга алынса да, Ершов артиллеристлар янына кача һәм аларны аякка бастыра. Аларга гарнизон кушыла. 24 нче октябрь көнне көндезге сәгать 11 ләр тирәсендә Казан өстендә артиллеристлар тарафыннан җибәрелгән шрапнель снарядны шартлый. Дошман авантюрасына каршы шул көнне бөтен хезмәтчел Казан күтәрелә. Елга арты ягындагы завод-фабрика гудоклары эшчеләрне Пороховой завод һәм Алафузов предприятиеләре янына җыя. Күп тә үтми, эшчеләрнең өч мең ярымлы гвардиясе һөҗүм башлап җибәрә. Елга аръягында гына да эшчеләр сафында өч йөздән артык татар була. Ә запас полклардагы өч мең ярым татар солдаты үзләренең революция эшенә тугрылыклы икәнлекләрен көрәш мәйданында күрсәтәләр. Шушы көчләрне оештыруда Мулланур Вахитов, Камил Якубов, Вәли Шәфигуллин, Галиулла Әхмәтов, Нәби Вахитов, Абдулла Рахманкулов һәм башкалар зур өлеш кертәләр. Николай Ершов, татарлар геройларча көрәште, дип искә ала.

25 нче октябрь көнне дошманның төп көчләре (ике мең ярым юнкер, берничә йөз солдат, офицер, казаклар, өч броневик) кызыл көчләрнең төрле яклап кысрыклаулары нәтиҗәсендә Кремльгә кереп бикләнә. Дошман лагеренда паника башлана. Таң алдыннан Петроградтан революциянең җиңүе турындагы телеграмма килеп төшә. Бу сөенечле хәбәр белән рухланган Казан революционерлары юнкерларны тулысынча тар-мар итә.

«Правда» газетасы бу вакыйга турында болай дип язып чыкты: «Керенскийга тугрылыклы булып калган кешеләр белән бер көнлек көрәштән соң властьны эшче һәм солдат депутатлары Советы яулап алды. Казан хәрби округы командующие Архипов һәм вакытлы хөкүмәт комиссары Калинин кулга алындылар». («Правда», 4 (17) ноябрь, 1917 нче ел).

26 нчы октябрь (иске стиль белән) кичендә Советның тарихи утырышында власть революцион комитет кулына тапшырыла. Шулай итеп, Казанда да Петроград белән бер үк вакытта диярлек Советлар власте урнаштырыла.

Ләкин аңарчы әле Лариса Казаннан чигенү ачысын татый. Аның гарьлеген, авырлыгын үз җилкәсендә тоя. Ул көннәрдә Лариса Михайловна Көнчыгыш фронтның Политбүлегендә эшли, яшь армиянең әле чыныгу алмаган, ныгып җитмәгән көчләрен Казанны саклауга туплау өчен нык тырыша. Инде шәһәрне калдырырга мәҗбүр булгач, ул соңгылар рәтендә чигенә, акларның көчле уты, өстәвенә бик каты яшенле яңгыр астында чыгарга туры килсә дә штабның печатьләрен, күп кенә яшерен кәгазь-документларын коткарып кала һәм аларны Свияжскига чаклы исән-сау китереп җиткерә.

Свияжскига чыгу белән, Казанда күп кенә җитәкчеләрнең калганлыгы беленә. Аларның язмышын ачыкларга, гомумән, шәһәрдәге хәл белән җентекләбрәк танышырга кирәк була. Бик тә җаваплы һәм куркыныч бу эшкә бер кызылармеец белән Рейснер алына.

Казанны алганнан соң аклар үзләренең төп максатларына — тимер юлга һәм Идел аша күпергә һөҗүмне дәвам иттерәләр. Безнең разведчиклар үтәргә тиешле юл өзлексез туп, пулемет уты астында була. Шулай да алар Казанга үтеп керәләр. Биредә безнекеләр акчехларның һәм акгвардиячеләрнең күп кенә ерткычлыкларының шаһиты булалар, акларның хәле, көче турында, алар кулында калган кызыл командирлар, активистлар турында мәгълүмат җыялар. Бу эштә Ларисаның үткенлеге, тапкырлыгы, шәһәрнең гади кешеләре белән уртак тел таба белүе нык терәк була.

Инде кайтып китәбез дигәндә генә, Рейснер аклар кулына, аларның да иң кансыз, иң явыз контрреволюционерлары Иванов кулына эләгә. Гомере кыл өстендә калганда да, ул өметсезлеккә бирелми, сабырлыгын, зиһенен җыеп, бәладан котылу җаен таба, үзенең кыюлыгы, тәвәккәллеге аркасында, гади кешеләрнең ярдәме белән ерткычлар тырнагыннан ычкына ала.

Бу хәл аны куркытып калдырмый — кыю хатын иң хәтәр разведкаларга йөрүен дәвам иттерә. Бу эшкә ул башка солдатларны, матросларны да дәртләндерә, үзенә ияртә. Озакламый аны яңа оешкан Бишенче армиянең разведка бүлеге комиссары итеп билгелиләр (14 августта чыгарылган 1 нче номерлы приказ).

Бу чорда разведка хезмәте аеруча зур әһәмияткә ия була. Комиссар Рейснер дошман турында мәгълүмат туплау белән бергә, Кызыл Армиянең төрле частьлары арасында, аеруча флотилия суднолары белән коры җир гаскәрләре арасында, элемтәне ныгытуга зур игътибар бирә. Разведка максатында ул төрле чаралардан: катер, гидропланнардан файдаланырга тәкъдим итә. Флотилия составында атлы разведка командасы булдыру да — аның инициативасы. Лариса Михайловна турында сөйләп калдырган истәлекләрендә аның көрәштәшләре гомер буе диңгездә йөзгән матросларның ничек итеп атка атланып йөрергә өйрәнүләрен кызык итеп, сагынып искә төшерәләр.


Шул ук вакытта Лариса Рейснер фронтның кайсы гына участогында булмасын — алгы сызыкта урнашкан латыш укчылары янындамы, флотилия канонеркаларындамы — үзенең политик комиссар икәнен бер генә минутка да онытмый, сугышчыларны ягымлы сүзләре белән көрәшкә, кыенлыкларны җиңәргә дәртләндерә. Шулай да коммунистның, комиссарның барыннан да көчле тәэсире иң кыен, иң җаваплы эшкә беренче булып үзенең ташлануы, революциягә чиксез бирелгәнлеге була.

...Берничә тапкыр аяусыз һөҗүмгә ташланып та тимер юлны һәм күперне ала алмагач, аклар астыртын юлга басалар: ата башкисәрләр Сафинков, Капельләр җитәкчелегендәге сайлап кына алынган офицер полклары безнең тылга, Тюрлема станциясенә бәреп кереп, Свияжскига ташланалар. Зур батырлык, ның ихтыяр көче туплап кына безнекеләр аларга каршы тора алалар. Шул сәгатьләрдә Тюрлемага барып, андагы хәлне ачыклап кайту ифрат та мөһим, кирәкле чара була. Дошман оясына берничә кызылармеец белән янә Лариса китә. Озак та үтми, ул хәлне ачыклый, шул хакта штабка телеграмма сугу җаен да таба. Шул документны каткат укыдым, разведка комиссарының кыюлыгы, акылы, зирәклегенә тагын бер кат сокландым мин. Ул бит бу юлы да аннан элекке разведкаларында да күргәнен хәбәр итеп кенә калмый, дошманга ничек ташлану, аны ничек җиңү юлларын да әйтә, кыю планнар тәкъдим итә.

Шуңа күрә дә без Казанны аклардан тартып алуда кыю комиссарның да өлеше бик зур дип, аңа бүгенге казанлылар исеменнән кайнар рәхмәтебезне белдерәбез. Дөрес, ул инде күптән юк, тиф аны нибары утыз яшендә якты дөньядан аерган. Ләкин Лариса Рейснер бүген дә безнең арада. Аны революциянең кайнар эзләреннән язылган, тарихи вакыйгаларны үзе күреп, үз йөрәгеннән үткәреп язган әсәрләре яшәтә. Ул үткер күзле, өлгер каләмле большевистик журналист, публицист булган, аның сугышчан очерклары, публицистик язмалары совет әдәбиятының алтын фондына кереп калды. Казан өчен, Идел өчен барган дәһшәтле көрәш эпизодлары, батырлык сәхифәләре яктыртылган «Фронт» циклы очерклары да шулар рәтендә. Аларга бүген, күргәнебезчә, тарихчылар да мөрәҗәгать итә, яшь журналистлар да язарга өйрәнә, әдәбият сөючеләр дә алардан тәм, ләззәт ала, яшәргә, көрәшергә өйрәнә.

Димәк, комиссар бүген дә безнең белән.

Илдар НИЗАМОВ.



Елга аръягы (Заречье) эшчеләреннән төзелгән кызыл гвардия штабы урнашкан йорт (Казан). Хәзерге Киров районының Гладилов һәм Табейкин урамнары чаты.

* * *

Алафузов предприятиеләре эшчеләреннән төзелгән кызыл гвардия отрядлары. 1917 нче ел, октябрь.



Мансур РӘХИМОВ рәсемнәре.



СОКЛАНДЫРГЫЧ ӘНИЛӘР, АПАЛАР

Әле хәтерегездәдер: 1970 елның гыйнварында бер атна буена көн дә рәттән өй борынча кереп йөргән кешеләрне күрдек. Аларның берсе безнең үзебездә дә булды. Өйдә вакытыбызны сагалап кына торган шикелле, барлык гаилә белән җыелып бетүебезгә килеп керде дә, алдан әзерләп куелган кәгазьләрен чыгарып, язарга әзерләнде һәм һәркайсыбызга бер үк сорауларын бирде.

— Гаилә башлыгының кеме буласыз? — беренче соравы аның шундый иде.

Күрәсез: иң элек гаиләнең башлыгы билгеләнде. Аннары, баш кешенең кеме булуыннан чыгып, һәрберебез тиешле җавабын куйды. Әйтик, түбәндәгечә:

— Хатыны.

— Улы.

— Кайнише...

Кайсы җенестән булуыбызны да яздылар, яшебезне дә теркәп куйдылар. Без аларның:

— Кайсы телне туган телегез дип саныйсыз?

— Белемегез нинди? — кебек сорауларына — барлыгы унбер сорауга җавап бирдек.

Халык санын шулай алу безнең илдә 1897, 1926, 1939, 1959 елларда уздырылган иде. Ә менә соңгы мәртәбә — 1970 ел башында үткәрелгән халык санын алу йомгаклары калын-калын җиде китап булып басылып та чыкты. Нибары унбер сорауга безнең кыска-кыска җавапларыбызны туплаган томнар алар. Димәк, безнең үзебез турында үзебез сөйләгән мәгълүматларны җыйган китаплар.

Җиде томлыкның махсус бер томына совет халыкларының белем дәрәҗәсен күрсәткән саннар җыйнап бирелгән. Мәсәлән, авыл һәм шәһәр халкын бергә кушып алганда, ил буенча мең кешегә 1959 елда югары белемле — 33, тәмамланмаган югары белемле — 9, махсус урта — 67, гомуми урта — 64, тулы булмаган урта белемле 260 хезмәт иясе, һәр өч кешенең берсе башлангыч белем белән булган. 1970 елга исә (ун ел эчендә) югары белемлеләр саны икеләтә, вузда укучылар бер ярым мәртәбә, махсус урта мәктәп тәмамлаганнар шулай ук бермә-бер диярлек, ә гомуми урта белем алганнар ике ярым тапкыр күбәйгән иде. Ә башлангыч белемлеләр өлеше күпкә кимеде. Ул чакта ук ун кешенең берсе югары, тулы булмаган югары, махсус урта белемле иде.

Экономик яктан үсеш дәрәҗәләренең тигезләшә баруы союздаш республика халыкларының культура дәрәҗәсе якынаюга илтә. Мәсәлән, илебездә 1939—70 елларда ун яшьтән алып шуннан өлкәннәр арасында югары һәм урта мәктәп тәмамлаганнар өлеше дүрт ярым мәртәбә артты. Бу үсеш саны Үзбәкстанда, Кыргызстанда һәм Таҗикстанда исә сигез-ун ярым тапкыр булды. Ә менә Башкортстанда утыз ел элек шундый белемлеләр меңнән 67 кеше булса, 1970 елда аларның саны 441 кешегә җитте. Мондый матур үзгәрешләрне илебез халыкларының һәркайсында күрәбез.

* * *

Җәмгыятьнең, һәр халыкның матди һәм мәдәни яктан үсеше анда хатын-кызның тоткан урыны, аның турында кайгыртучанлык күрсәтү дәрәҗәсе белән дә билгеләнә, дигән хакыйкать бар.

Совет властена ярты гасыр тулган елда Татарстанда үткәрелгән социологик тикшеренү мәгълүматлары күрсәткәнчә («Социальное и национальное», «Наука» нәшрияты, Мәскәү, 1973 ел), 1968 елда республикадагы бар белгечнең 61,3 проценты хатын-кызлар иде, ә татарлар арасында бу процент башка милләт вәкилләре белән чагыштырганда зуррак (63 процент) булды. Димәк, татар хатын-кызлары белемгә, фәнгә омтылышта ирләреннән уздырдылар.

Социологлар безнең Казан, Минзәлә һәм Әлмәт шәһәрләрендә яшәүчеләребезгә шундыйрак сораулар белән мөрәҗәгать иткәннәр:

— Нинди газета-журналлар алдырасыз?

— Шәхси китапханәгез бармы?

— Кино-театрга еш йөрисезме?

— Музейларда, күргәзмәләрдә буласызмы?

Рухи дөньябызның ни дәрәҗәдә бай булуын алар шулай белергә теләгән. Мәгълүматлар әйтеп тора: хатын-кызлар культура һәм рухи ихтыяҗлары ягыннан Казанда ирләрдән калышмыйлар. Минзәләдә исә, киресенчә: аерма 15—20 процентка тигез, монда ирләр культура байлыкларыннан активрак файдаланалар. Әлмәттә дә шундый ук тенденция, тик анда аерма 5—8 проценттан артмый.

Мондый күренешнең сәбәпләре ерак яшеренмәгән булса кирәк: Казан — иске гореф-гадәттән күбрәк арынган шәһәр, анда тормыш-көнкүреш шартлары яхшырак. Әлмәттә исә, чагыштырмача яшь шәһәр булганлыктан, культура-көнкүреш хезмәте арттарак кала, биредә әле гаиләләр йорт хуҗалыкларыннан аерылып җитмәгән. Ә Минзәлә исә ярым авылча яши, бакча, мал-туар да бар, нәтиҗәдә хатын-кыз күбрәк хозяйка хәлендә кала бирә. Ләкин театр-концертларга йөрергә, кино карарга, музыка тыңларга шулай да вакыт таба.

* * *

Ә авыл хатын-кызлары, гомумән алганда, ирләрдән белем ягыннан бераз калышалар. Утыз яшькәчә хатын-кызлар исә бу җәһәттән ирләрнең үзләрен артта калдырдылар.

Шушы фактта галимнәр бик зур мәгънә күрәләр, чөнки бер буын гомере эчендә үткән заманнан килгән социаль тигезсезлек бетерелде дигән сүз бу!

* * *

Эштән тыш буш вакытны ничек файдалану шулай ук кешенең рухи йөзен, аның тере яки бу рухи ихтыяҗын билгели. Шуны истә тотып, галимнәр авылдагы замандашларыбызга төрле сораулар белән мөрәҗәгать иткәннәр.

Буш арада кем ни белән шөгыльләнә:

— Йорт эшен башкарамы?

— Радио тыңлыймы?

— Кино-танцыга йөримә?

— Китап укыймы?

— Үзешчән сәнгатьтә катнашамы?

— Дәрес әзерлиме?

Татарлардан 46 процент авыл кешесе даими рәвештә укудан өзелми. Радио хезмәткәрләре горурлана ала: һәр дүрт кешенең өчесе, хәтта күбрәк тә әле, радионы даими тыңлап яши. Шунысын да әйтергә кирәк: радио җыр-музыка, әдәби тапшырулары белән үзенә тарта. Авыл эшчәннәренең бөтенесе диярлек татар музыкасы тапшыруны үтенә. Шунысы кызыклы: авыл күбрәк хәзерге заман җыр-көйләрен үз итә.

Ул елларда татар районнары, мең кешегә исәпләгәндә, үзәк матбугатны — 250, республика матбугатын 540 (шул саннан — русча 60) данә алдыра иде.

Барлык төр (хор, бию, драма, техник) үзешчән түгәрәкләрдә мең кешенең 102 се катнаша. Шунысы игътибарга лаек: электә

куптавышлы җыр сәнгате булмаган татар халкы мондый түгәрәкләргә торган саен күбрәк йөри. Рәсем, кино һәм фото сәнгатендә, әдәби иҗатта үзешчәнлек чагыштырмача азрак үсеш алган.

Гаилә һәм көнкүреш хәлләренә күз ташласак, шуны күрәбез: физик хезмәттәге татар хатын-кызларының белем дәрәҗәсе совет власте елларында 20 тапкыр үскән. Хатыннарның егерме проценты хезмәт хакын ирләреннән күбрәк ала.

Мондый хәл «мин — баш, хатын — муен» дип ялгышып йөрүче ирләрне уйландырырга тиештер.

Яшь хатын-кызлар җәмәгать эшләрендә актив катнаша: 35 яшькәчә хатын-кызларның 88 проценты— агитаторлар, пропагандистлар, лекторлар. Аларның миссиясе — халыкның барлык катламнарына да культура, аң-белем илтү, хатын-кызлар бу бурычны күңел салып башкаралар. Чөнки барысы да диярлек бу эшләрен халык өчен дә, үзләре өчен дә файдалы дип саный.

Галимнәр шундый сорауларга да җавап алганнар:

— Буш вакытын күбесенчә йорт эшләренә, балалар карауга бирәме!

— Бакчалы, сыерлымы!

— Газета, матур әдәбиятны даими укып барамы!

— Аена бер мәртәбә кинода буламы!

— Коллективта мөһим мәсьәләләрне хәл кылуга тәэсир итә аламы!

Авылда яшәүче хатын-кызларыбызның күпчелеге бала-чагасы ишле, йорт хуҗалыгы мәшәкатьләре булуга карамастан, вакытында кино-театрга йөрергә дә, концерт тыңларга һәм үзе сәхнәдә чыгыш ясарга да, китап укырга һәм авылдашларын агартырга да өлгерә. Әлбәттә, аларның коллективта да мөһим мәсьәләләрне хәл иткәндә сүзе үтә.

Күреп үткәнебезчә, Академия галимнәренең тикшеренүләре шуны раслый: бүгенге, яшь буын хатын-кызларыбыз эшенең характеры, эчтәлеге, хезмәт хакы, тормыш-көнкүреш рәвеше, гаиләдә тоткан урыны белән дә әниләреннән, кайнаналарыннан аерылып торалар.

Бөек Октябрьның куанычлы, татлы җимешләре болар.

Хәмзә ЗАРИПОВ.

МАКТАУГА ЛАЕКЛЫЛАР

«ОКТЯБРЬ — БӘХЕТЕМ ЯЗМЫШЫ»



Закирова ФӘУЗИЯ, Казан фотожелатин заводының Октябрь Революциясе орденлы өлкән аппаратчысы.

— Мин бүген ихлас күңелдән: «Бәхетлемен», дип әйтә алам икән, моның өчен мин иң элек Бөек Октябрьга бурычлы. Илдә Октябрь революциясе җиңеп чыкканга гына мин яраткан һөнәремне үзләштерә алдым. Хәзер мин иң югары разрядлы аппаратчы. «СССРның химия промышленносте отличнигы», «СССРның почетлы химигы» дигән исемнәрем бар.

Бу заводта әтием дә эшләде, әнием дә эшләде, минем эшли башлавыма да бераздан утыз ел тула, кызым Нурдидә дә шул ук заводта экономист булды. Коллектив — гаиләмә, цехым икенче өемә әйләнде. Төрле яклап бай мин. Әнә нинди зур гаиләм, сүзем үтәрдәй күпме дусларым бар. Икенчедән, тормышым да нык. Хезмәт хакым яхшы. Квартирам замананың иң шәп итеп салынган өендә. Анысын да завод бирде. Эч пошырып тора торган бер генә мәшәкатем дә юк.

Хезмәт юлына басуымның беренче елларында ук миңа хөрмәт күрсәттеләр. Бөек Ватан сугышы елларында намуслы эшләгән өчен медаль алдым. Анда миңа нибары егерме ике генә яшь иде әле.

Тора-бара медальләрне тагын бирделәр. Инде менә бик зур дәрәҗәле Октябрь Революциясе орденым да бар. Болар барысы да — миңа ышаныч күрсәтү җимешләре.

1948 елны мин кулыма берсеннән-берсе нәнирәк ике кызымны күтәреп тол калдым. Шунда да сәртенергә ирек бирмәделәр. Балаларымның берсе институт, икенчесе техникум тәмамлады. Үзем 1950 елдан бирле коммунистлар сафында. Завод эшеннән бушаган арада гел кешеләр арасында булам, җәмәгать эшләре башкарам. Шәһәр Советы депутаты итеп тә сайладылар, КПСС райкомы члены да идем, заводта да әле партбюрога, әле завкомга сайлыйлар. Ул вазифаларымны да җиренә җиткереп үтәргә тырышам.

Иң зур куанычым — заводтагы эшем, әлбәттә. Элек бары тик фотография тасмасы ясардай гына желатин чыгарган безнең предприятие бүген азык промышленностена да, фото белән киноға да, медицинага да ярарлык желатиннар бирә. Калдык-постыкларыбыз авылларга озатыла, җир ашлауга китә. Продукциябезне чит илләрдә теләп-сорап алалар. Әле күптән түгел безнең желатинны алучы илләрдән: ГДР, Венгрия, Польша, Чехословакиядән бер төркем кунаклар килгән иде. Завод белән таныштылар. Тиз арада дуслаштык. Аннары заводның иң уңган кешеләре аларны даһи Ленин туган Ульяновск шәһәренә сәяхәткә алып бардылар. Ул төркемдә мин дә бар идем. Сәяхәттән күңелем тагын да күтәрелеп кайтты.

ТУНИС БУЙЛАП



БЫЕЛ ҖӘЙ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ҖЫР ҺӘМ БИЮ АНСАМБЛЕ ТУНИСТА ҮТКӘРЕЛГӘН ФОЛЬКЛОР ФЕСТИВАЛЕНӘ КАТНАШТЫ. БУ СӘФӘР ТУРЫНДА ИРКЕНЛӘБРӘК СӨЙЛӘШҮ ӨЧЕН, ЖУРНАЛНЫҢ ШТАТТАН ТЫШ ХӘБӘРЧЕСЕ, МУЗЫКА БЕЛГЕЧЕ КЛАРА ТАҖИЕВА АНСАМБЛЬНЕҢ ДИРИЖЕРЫ ВЕНЕРА ГӘРӘЕВА БЕЛӘН ОЧРАШТЫ ҺӘМ ТҮБӘНДӘГЕ ӘҢГӘМӘНЕ ОЕШТЫРДЫ.

Сорау: Чит илгә чыгып концертлар бирү сездә нинди тәэсирләр калдырды?

Җавап: Көткәнгә караганда да яхшырак. Безнең коллектив бу фестивальгә бик зур җаваплылык тоеп әзерләнде. Чөнки безнең Тунистагы чыгышлар бер Татарстан исеменнән генә түгел иде. Без анда Советлар иле вәкилләре буларак катнаштык һәм безнең һәр адымыбыз совет кешеләре турындагы фикерләрне акларга тиеш иде.

Каушау кебек хәвефле хисләр, бәхеткә каршы, Туниска аяк басу белән үк юкка чыкты. Безне бик җылы каршыладылар. Үзебез яшәргә тиешле торак янына килеп туктаган гына идек, тунислылар һәм фестивальгә килгән башка ил кунаклары камалышында калдык. Йөзләрдә — елмаю. Барысы да: «Ура-а! Совьетик!» — дип кычкыралар, кул чабалар. Әле бит бик иртә, сәгать өч кенә иде. Шуңа карамастан, Франция, ГДР, Сөгуд Гарәбстаны артистлары, йокыларыннан торып, безне, илле кешелек группабызны сәламләргә чыкканнар.

Шул минуттан күңелләр күтәрелеп китте, иҗат дәрте өстәлде, фестивальне уңышлы уздырып җибәрү теләге белән яна башладык.

Сорау: Нинди рәк фестиваль иде соң ул?

Җавап: Төрле илләрнең халык сәнгатен күрсәтүгә багышланган бу фестиваль борыңгы Карфаген амфитеатрында ике елга бер тапкыр үткәрелә. Быел аңа утыз биш илдән килделәр. Коллективлар арасында халык музыкасын пропагандалаучы профессиональ группалар да, һәвәскәрләр дә бар иде. Һәр коллектив өч программа әзерләгән: унбишәр минутлык ике концерт һәм ярты сәгатьлек тагын бер концерт.

Йомгаклау концерты унмең тамашачы сыйдырышлы Карфаген амфитеатрында булды. Бу, әлбәттә, иҗат коллективының осталыгына зур сынау иде. Сынауны уңышлы үттек, безнең чыгышлар тоташ кул чабулар белән узды.

Безгә бик күп чыгышларны карарга, әллә никадәр җырлар ишетергә мөмкин булды.

Сорау: Кайсы ил вәкилләренең чыгышы аеруча ошады сезгә?

Җавап: Арада Палестинадан килгән артистлар чыгышы аерылып торды. Аларның бөтен программасы ил язмышын чагылдыруга бәйле. Костюмнары да хәрби киемгә тартым, кулларында — автоматлар. Алар аны ике бармакны тырпайтып күрсәткән рәвештә күтәрәләр. Бу аларда ирек һәм бәйсезлек символы итеп йөртелә икән. Палестиналыларны бөтен зал аягүрә басып алкышлады. Милли азатлык хәрәкәтен, көрәшчеләрне хуплау иде бу.

Африка илләреннән килгән артистларның чыгышы динамизм, көрәш рухы белән аерылып торса, Европа вәкилләренең концерты тыныч, салмак агымга көйләнгән иде.

Сорау: Карфаген фестивалендә утыздан артык милләт вәкиле катнашкан. Сез бер-берегезне ничек аңлаштыгыз, аралашу кыен булмадымы соң?

Җавап: Бу урында мин шуны искә төшерер идем: сәнгатьне аңлау өчен телне белү кирәкми. Тунисга без бу хакыйкатькә ихластан ышандык. Халыкларыбыз сәнгатенә булган ихтирам, аңа бирелгәнлек, аңа хезмәт итү, аңа тугрылык безне тиз дуслаштырды. Сүзсез аңлаша башладык. Сәнгать көче үзенекен итте.

Сорау: Сез Туниснын башка шәһәрләрендә дә булдыгызмы?

Җавап: Әйе. Бәхеткә каршы, фестивальгә катнашучылардан бары безнең коллективка гына аерым тәкъдим ясалды. Татарстан артистлары Туниснын Монастир, Сусс, Бизерта, Мензель-Бургиба, Матер, Тибурба, Әл-Алиа, Мензель-Җәмил, Силиана, Кайруан шәһәрләрендә дә концерт бирделәр. Сәгать ярымлык программа белән унбиш тапкыр чыгыш ясадык.

Зал шыгрым була. Һәр шәһәрдә концертларга зурзур җитәкчеләр килә иде. Чыгышларыбыздан соң рәхмәтләр әйтәләр, истәлекле бүләкләр тапшыралар, яңадан очрашырга теләүләрен белдерәләр.

Сорау: Концертларны оештыруда үзенчәлекле алымнар күренмәдеме?

Җавап: Күренмәгән кая! Башта аптырап калдык. Анда афишаларга гына ышанып тормыйлар икән. Концерт башланырга бер-ике сәгать кала, урамга репродукторлы машина чыга. Концертта катнашучылар исә җырлый-җырлый машина артыннан барырга тиешләр. Өстебездә — концерт костюмнары. Халык шау-гөр килеп безне урап ала. Җырыбызны ошатканнар безгә ияреп концерт булырга тиешле бинага керә.

Тунис тамашачысының сәхнәгә мөнәсәбәте дә кызык. Чыгыш ошаса, кул чабып кына калмый, сиңа кушылып җырлый башлый, көйне яратса, баскан җирендә тыпырдап куя. Гаҗәп!

Сорау: Сезнең программада нинди рәк әсәрләр бар иде?

Җавап: Программабыз ике өлештән тора иде. Беренчесендә без «Аулак өйдә» дип исемләнгән җырбиюле күренешне сәхнәләштердек. Аны бик яхшы кабул иттеләр. Күрәсең, бу сюжетта күрсәтелә торган хәлләр башка халыклар тормышына да хас. Аннары баянчыбыз Рәшит Мостафин кечкенә гармуннарда татар халык көйләрен уйнады. Ул безнең бик тапкыр. Кай арададыр, гарәпләрнең иң популяр көен отып калган. Сәхнәдән дә шуны уйнаган иде, тыңлаучылар аңа кушылып җырлый ук башладылар.

Аннары аерым җырлар, биюләр китте. Нәфисә Васыйлованың «Кәк-күг»ен, «Киек казлар»ын бик яратып тыңладылар. Гали Ильясов рус халык җыры «Калинка»ны җырлаганда, тамашачылар урыннарында утырып тора алмас хәлгә килделәр. Эмиль Җәләлетдиновның «Кара урман»ын алар тын да алмый тыңладылар. Эльвира Хәбибуллина чыгышы исә аларны тагын да сәерсендереп калдырды. Бу илдә колоратуралы сопрано тавышы ят нәрсә икән. Эльвира, сандугач булып «сайрый» башлагач, бөтенләй аптырадылар.

Сорау: Тунисга көнкүреш ничек? Һава хәлләре нинди булды?

Җавап: Африканың төньяк өлешенә урнашкан бу ил мөстәкыйль тормышка күнегеп кенә килә әле. Безнең өчен бик гаҗәп тоелган хәлләр дә шактый. Мәсәлән, 7—8 яшьлек балалар, һөнәр иясе булып, көнкүрешкә кирәкле төрле әйберләр ясыйлар да үзләре үк шуны сатып йөриләр. Базарларында үзеңне музейда йөргән кебек хис итәсең. Барысы да кулдан ясалган вак-төяк сата. Келәмнәр, комганнар, чүкеләп ясалган сурәтләр... Бизәкләре бик бай.

Һава шартлары безнең өчен ярыйсы тоелды. Быел җәй Казанда да нәкъ Тунистагыча 35 градуслы җылылык торды бит. Елга буйларында олеандрлар чәчәк атып утыра. Еракта карлы тау түбәләре күренеп тора. Матур.

Тунис халкы безгә туганнарча мөнәсәбәттә булды. Яшьләрнең кайберләре СССРда белем ала икән. Алар русча яхшы сөйләшә. Җәлил шигырьләрен, Пушкинны, Тукайны беләләр.

Сорау: Нинди уйлар белән кайттыгыз?

Җавап: Юлга җыенганда, ничек дулкынланган булсак, чит илдә казанган уңышлардан тагын да ныграк каушап калдык. Безнең бит дөньякүләм халыкара



бабай» (Н. Фәттах), «Көмеш пешерүчеләр» (Р. Фәйзуллин) һәм тагын дистәләрчә башка китапларда, «Ялкын» журналына, «Яшь ленинчы» газетасына ясалган иллюстрация-рәсемнәрдә үзенең мәшәкать-борчулары, кайгы-шатлыклары, зәңгәр хыяллары белән Суфия Насыйрова ачкан гаҗәеп кызыклы балалар дөньясы яши.

Суфия Насыйрова бизәгән «Нечкәбил» (А. Алиш) китабын укыган һәм рәсемнәрен күргән балаларның һәркайсы бал кортларына гади бөҗәк итеп кенә карый алмый торгандыр, мөгаен. Бакчы, рәссам хыялы аша карасаң, нинди сылу икән ул бал корты — озын күлмәк итәкләрендә алтынсу сырлар, җиңнәре ак, муенсасы гәрәбәдәй, күзләре зур, карашы акыллы. Нинди олы булып күренә икән аңа яфраклар, чәчәк таҗлары — һәркайсы өй түшәме кадәр. Нинди ди чит кеше, эшләпәсен күтәрә төшеп.

Аның кыяфәтендә ялагайланып елмаюның, куштанлыкның, ярарга тырышуның, «артыма типсәң, тип, йомышымны гына йомышла», дип ялынуның бөтен төсмерләре чагыла.

Икенче бер рәсемдә («Чаян», 1976, 5 нче сан) яшь кенә кыз укытучы янына имтихан тапшырырга килгән.

— Я, мин сезне тыңлыйм, — ди имтихан алучы.

— Сөйләшмичә генә утырыйкчы, — дип җавап бирә кыз, курчакларныкыча озын керфекләрен түбән сирпеп. Кыз йөзендәге беркатлылык битлеге астыннан хәйләкәрлек билгеләре, яшерен көлемсерәү сирпелә. Ләкин укытучыга аның бу халәте сизелми дә сыман. Чөнки ул әлеге җавапны чын дип тә, тапкыр шаярту дип тә, әрсезлек дип тә кабул итә алмый. Кызның яшьлеге һәм

КАЕН ҖИЛӘГЕ

ларга, бала күңелендәге яшерен почмакларга үтеп керә белергә кирәктер. Алай гына да түгел, бу өлкәдә иҗат итүче рәссамга бала хыялының канатларын күрү һәм очыш биеклеген чамалау сәләтенә ия булырга кирәктер әле. Ә Суфия Насыйрова иҗатында нәкъ әнә шундый сыйфатлар өстенлек итә.

Илдар Юзеевның «Пони малае Җирәнкәй» китабындагы дистәләрчә иллюстрацияләр арасыннан берсенә генә тукталып үтик.

...Тезләрен бөкләп җирдә яткан Пони малае кайгылы. Аның күзеннән сөйлән бөртегедәй яшь тама. Аның каршында, шулай ук тезләрен бөкләп, учы белән җиргә таянып, бер малай утыра. Малай еламый, ләкин аның гөнаһсыз күзләрендә, бераз турсаебрак ярым ачык калган иреннәрендә, югары күтәрелеп киткән кашларында, куе сипкелләрендә сөйләп бетергесез тирән кызгану хисе — әгәр хәленнән килсә, тамчы да уйлап тормас иде малай — Җирәнкәйне песи баласы шикелле куенына кыстырыр иде дә, бөдрә яллы маңгаеннан сыйпый-сыйпый, юатыр иде шикелле. Малайның йөзенән кызгану хисе белән бергә бәлага тарган колынга ярдәм итү, аның кайгысын җиңеләйтү бәрабәренә үзе кыенлыклар кичерергә әзер тору теләге дә чагыла. Төсләренең кискен контраст ясамыйча, йомшак кына аралашуы Җирәнкәйнең кайгысын тагын да тирәнәйтә, малай күңелендәге тойгыларны тагын да нечкәртә, аның самими теләкләрен тагын да көчәйтә сыман.

Гадәттә, ярдәмче детальләр әсәрнең композициясен генә тулыландыралар. Ә Суфия Насыйрова иҗатында исә алар рәсемнең сюжетын ачарга да, фикерен расларга да ярдәм итә. Югарыда телгә алынган рәсемдә дә шулай: күп сөйләргә яратучы тутый кош та әнә, колын кайгысын һәм малай кичерешләрен уртаклашырга теләгәндәй башын иеп, тынып калган.

«Пони малае Җирәнкәй» (И. Юзеев), «Күңелле сәфәр» (Ш. Галиев), «Безнең эре һәм хәвефле икән аның өчен яңгыр тамчылары — һәркайсы галәм океаныннан күк гөмбәзенә үтеп кергән йолдыз кыйпылчыклары кебек...

Әдәби әсәрләргә ясалган иллюстрацияләр — Суфия Насыйрова иҗатының бер тармагы гына. Моннан тыш әле ул үзе туып үскән шигъри Арча якларының киң басуларын, урман-суларын, юмарт табигатен, яшь замандашларының рухи дөньясын чын сәнгать югарылыгында чагылдыра торган тирән эчтәлекле, фәлсәфи яңгырашка ия булган картиналар да иҗат итә.

Киров районының пионерлар сарае каршындагы изостудиягә йөргән һәм Казан сәнгать училищесында укыган елларыннан бирле аның акварель эшләреннән аерым күргәзмәләр оештырылып килә һәм яшь рәссамның иҗаты һәрвакыт югары бәяләнә.

Бервакытны әдәбият, сәнгать тирәсендә чуалучылардан берәү, сатира-юмор жанры турында сүз чыккач, телсә-нинди карикатура кеше шәхесен мыскыл итү, дигән иде. Бәхәсләшмибез, бәлки, өлешчә ул хаклы да булгандыр. Тик Суфия Насыйрова карикатуралары белән танышса, ул кешенең фикере, һичшиксез, үзгәрер иде. Чөнки Суфия Насыйрованың сатира-юмор әсәрләре дә балалар дөньясыннан килә торган садәлек, самими шуклык, эчкерсез шаянлык тойгылары белән сугарылган. Юк, бу сыйфат карикатураларның көлдерү көчен киметми, киресенчә, рәссам фантазиясен реаль җирлеккә ныграк бәйләү белән бергә, сатирик яки юмористик ситуацияне киңәйтебрәк җибәрә, көлү объектының тәэсир итү көчен арттыра, игътибарны рәсемнең фикеренә, мәгънәви ягына юнәлтергә ярдәм итә.

«Деканның имтихан алды мажаралары»нда («Чаян», 1977, 14 нче сан) декан иртә белән кырынырга дип көзгә алдына килсә, ни күзе белән күрсен — көзгедән үз шәүләсе урынына чит кеше карап тора.

— Мин сезгә улымны институтка урнаштыру йомышы белән килгән идем, — балкып торган чибәрлеге каршында зиһене тәмам чуалган аның.

Рәссамның карикатуралары усал сатирадан бигрәк шаян юморга якын, аларга җылылык, яктылык һәм көлдерү сыйфаты хас.

Суфия Насыйрованың таланты сатира-юмор жанрында елдан-ел ачыла бара. Хәзер ул — «Чаян» журналының үз кешесе. Җыелышларга йөри, журналга темалар сайлау, карикатуралар кабул итү утырышларында эшлекле тәкъдимнәр әйтә, редакция вәкиле буларак, халыкара күргәзмәләргә катнаша. Әле менә шушы елның язында, башкалабыз Мәскәү шәһәрендә «Сатира тынычлык өчен көрәштә» дигән III Халыкара күргәзмәдә «Чаян» журналы рәссамнары коллективы диплом белән бүләкләнде. Бүләкләнүчеләр арасында, әлбәттә, Суфия Насыйрова да бар иде. Быелгы яз рәссамга, гомумән, зур уңышлар, истә калырлык шатлыклар китерде. Габровода (Болгария) үткәрелгән «Дөнья, көлгәнгә күрә, имин калды» дигән Халыкара күргәзмәдә дә аның рәсемнәре бүләккә лаек булды. «Сатира ут сызыгында» (1970), «Чили халкына ирек» (1974) дигән күргәзмәләрдә политик темага ясалган карикатуралары өчен Суфия Насыйрова шулай ук дипломнар, истәлекле медальләр алган иде.

Бүгенге көндә Суфия Насыйрова яңа иҗади янулар кичереп яши. Күргәзмәләргә әзерләнә, «Крокодил», «Чаян» кебек сатирик журналларга карикатуралар ясый. Күренекле шагыйрь Яков Акимның «Филләр», «Көймәдә» һәм башка шигырьләре буенча төшерелечәк диафильмнар өчен иллюстрацияләр иҗат итә.

Сандугачлы җәйнең чык суларыдай пакь, таңнардай алсу беренче җиләкләре табигатькә аерым бер сафлык, гүзәллек өстәгән шикелле, Суфия Насыйрованың яңа рәсемнәре дә кешеләр күңеленә һәрвакыт шатлык, яктылык, рухи күтәренкелек алып килә.

Фаил ШӘФИГУЛЛИН.

«Сине иҗат итеп, үзем бар буламын»



СССРның ҺӘМ РСФСРның ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯЛӘРЕ ЛАУРЕАТЫ, БАССРның САЛАВАТ ЮЛАЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ, БАШКОРТСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ МОСТАЙ КӘРИМ БЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯДӘ КУНАКТА БУЛДЫ. ДУСЛАРЧА ӘҢГӘМӘ ВАКЫТЫНДА БЕЗ АҢА ИКЕ СОРАУ БИРДЕК.

1. Сезнең фикерегезчә, бүгенге чор әдәбиятына хас сыйфатларның иң мөһиме нинди?

Мәгълүм булганча, әдәбиятның, сәнгатьнең иң төп сыйфаты — аның заманга, социаль шартларга мөнәсәбәте белән билгеләнә. Ул яки тормыш белән конфликтка керә, яисә тормыш белән гармониядә яши.

Бүгенге көндә капиталистик илләрдә прогрессив сәнгать һәм әдәбият тормышның нигезләрен үзгәртү өчен көрәшә, чөнки капитализм кешене кимсетүгә корылган, ә чын сәнгать моның белән ризалашып яши алмый. Шунлыктан ул бу система белән килешмәс конфликтка керә. Көнбатышның прогрессив әдәбияты моңа бик ачык мисал булып тора.

Совет әдәбияты исә ил тормышы белән, халык тормышы белән тулы гармониядә яши, тормышның нигезләрен, принципларын, киләчәкнең максатларын раслау өчен көрәшә. Чөнки безнең җәмгыятебез кешелекнең меңәр еллык идеалларының реаль чагылышы буларак төзелде. Бездә тормыш идеаллары белән сәнгать, әдәбият идеаллары тәңгәл килә.

Ләкин бу әле әдәбият тормыш белән чөңгердәшеп кенә яши дигән сүз түгел. Әгәр алай булса, әдәбият үзен-үзе үлемгә дучар итәр иде. Безнең әдәбиятыбыз тормыш белән даими бәхәскә керә, якты идеалларның тагын да тулырак тормышка ашуы өчен, матур киләчәк өчен көрәшә. Чын талантлы әдәбият киләчәкне алдан ук күреп яши.

Киләчәкнең таләпләре өчен бүгенге чынбарлык белән бәхәскә керү әдәбиятның, сәнгатьнең үсеше өчен зарур булган драматизмны тудыра да.

2. Бүгенге көн укучысына хас иң төп сыйфат нинди?

Безнең укучыларыбыз искиткеч күп. Бу бигрәк тә чагыштырып караганда ачык күренә. Китапларның тиражын гына алыйк. Капиталистик илләрдә чыккан китапларның тиражы безнеке белән чагыштырганда гаҗәп аз бит! Франциядә, мәсәлән, күп китаплар 200, 500 данә чыгарыла, ә бездә тиражлар йөз меңләп, миллионлап санала.

Әйе, укучыларыбыз күп, аларның саны арта бара. Ләкин һәр укучы үзе бер планета, үзе бер дөнья бит ул. Бик күпләр әдәбиятны дөрес аңлыйлар, әдәби әсәрләрдән үзләрен борчыган сорауларга җавап эзлиләр.

Ләкин фикере оеган, әдәби әсәрләр укуга вакыт үткәрү чарасы итеп кенә караган укучылар да бар. Алар детектив, мажара белән мавыгалар, укыйлар, ә фикерләре йоклаган була, үсми. Бу язучыларга мөнәсәбәттә дә сизелә. Андый укучылар телендә шагыйрьнең

Мостай КӘРИМ

9 нче Май

Борынгы Персиядә әҗәткә алу хурлык саналган.

Геродот буенча

Туган илем! Һаваларга ашкан
Шөһрәтеңнең хаклы байраклары.
Җир шарының ике яртысында
Салютыңның балкый шандаклары[1].

Шундый чакта мин я чүгеп төшәм,
Я күкләргә тия түбәләрем.
Бер карасаң, үзем балкыш, имеш,
Бер карасаң, бары күләгәмен.

Ни булсам да, рәхимеңә рәхмәт.
Миңа ышандың кара көннәреңдә.
Башкаеңа төшкән бәлаләрдән
Өлеш салдың минем иңнәремә.

Мин яраклы булдым чыдамыңа,
Каткан сынык, татыр суларыңа.
Һәм яраклы булды минем каным
Синең туфрагыңны сугарырга.

Җиңүеңә мин яраклы булдым.
Хәйран шәмнәр синдә кабынганда,
Бәйрәмеңә мин яраклы булдым —
Читкә тибәрмәдең табыннарда.

Рәхмәт, илем! Бирсәң, үлчәп бирдең,
Кылганыма хакны таманладың.
Мактар булсаң хәттин ашырмадың,
Чама белән генә ямanladың.

Кимсетмәдең син, әҗәткә биреп,
Икмәк, тоз, су, бүләк, дәрәҗәләр.
Бик бәхетсез иткән булыр идең,
Син бурычка бәхет бирсәң әгәр...

[1] Шандаклары — балкышлары

* * *

Без өчәү бу таңда —
Син, җиһан, мин.
Юк нәрсә юк монда: зыр әйләнә
Планеталар. Бал кортлары оча,
Таулар тетри, күкләр семәрләнә.

Юк нәрсә юк монда: баш калкыта
Алчак, сабый үлән кыяклары,
Кош юлыннан чапкан боланнарның
Очкын чәчә көмеш тояклары.

Без өчәүбез бу мәл —
Син, җиһан, мин.
Вакыт тынсын, какма күз керфегең.
Кага күрмә. Әле таммый торсын
Керфек очындагы яшь бөртеге —
Минем яшь бөртегем...
Син хәйрансың —
Җиһан сыйган синең карашыңа.
Ә мин сокланамын бары сиңа —
Замананың бер кыз баласына.

* * *

Имеш, сине ходай яраткан, ди,
Чалыш кабыргадан.
(Әйтерсең лә, аңа шуннан кулай
Нәрсә табылмаган...)

Дөрес түгел! Сине мин яраттым
Уттан, судан, нурдан,
Бетмәс хыял, сүнмәс өметләрдән
Һәм бер моңлы җырдан.

Газап куштым, янә шик өстәдем —
Әчкелтем тәм салдым,
Шатлыкларның кадерен белү өчен
Аз гына гамь салдым.

Айлар... Еллар...Гомер буе шулай
Сине бар кыламын.
Сының, рухың камилләшкән саен
Синнән тартынамын.

Күзләреңнең тылсымыннан каушап,
Хәтта зар буламын.
Ә шулай да, сине иҗат итеп,
Үзем бар буламын.

* * *

Гашыйклар, сезгә эндәшәм —
Юк-барга җан кыйнашмагыз.
Бозылышу чирек әҗәл.
Әҗәл белән сынашмагыз.
Араларга ышанмагыз,
Вакытларга таянмагыз.
Аерылышу — ярты әҗәл.
Әҗәл белән шаярмагыз.
Ә шулай да, сөю барда,
Төзәлмәслек яралар юк.
Сөю сүнсә, кеше үлә.
Әҗәлләрдән чаралар юк.

исеме әсәрләреннән алда йөри, ә прозаикның исеме әсәрләреннән артта йөри. Кайберәүләр мине күргә: «Ә, Мостай Кәриммени, беләбез, беләбез!» — диләр. «Нинди әсәрләремне беләсез?» — дип сорасаң, бер шигырьне дә искә төшерә алмыйлар Шул ук вакытта калын-калын романнар укып чыгалар, ә авторның исеменә дә игътибар итмиләр.

Бу — әдәбиятка бик өстән караудан, фикерсез булудан килә.

Минемчә, әдәби әсәрне уку кешедән аз гына булса да зиһен хезмәте таләп итәргә тиеш, укыганда аның акылы, хисе, хыялы хәрәкәттә булырга тиеш. Югыйсә уку — буш эш булып кала.

Күп кенә очракларда без укучының төрлелеген исәпкә алып бетермибез, аңа артыгын ярарга тырышабыз. Ә укучы язучыга үз таләбен куя. Мәсәлән, язучы врачлар янына барса, аңа, медиклар турында китап языгыз, диләр, тегү фабрикасына барса, тегүчеләр турында язуын үтенәләр. Бер карасаң, алар хаклы да кебек. Ләкин һәр язучының үз иҗат мохите бар бит. Язучыга нәрсә хакында язарга икәнен төртеп күрсәтү кирәкми. Бу — язучыны көчләү булып чыга бит! Күпләр моны аңлап җиткермиләр. Минемчә, язучы да укучыга үз таләбен куярга хаклы. Укучыны актив укырга, әдәбиятның асылына үтеп керергә өндәргә кирәк. Без укучының зәвыгын формалаштырырга тиешбез.

* * *

Шул ул көнне кич язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубында Мостай Кәрим белән очрашу булды. Шагыйрь үзенең яңа шигырьләрен укыды, күп санлы укучыларның сорауларына җавап бирде.

Шагыйрь безнең журналга соңгы вакытта язган шигырьләрен тәкъдим итте.

* * *

Бурап ла гына бурап карлар ява,
Боекмыймы болан баласы.

Җырдан.

Өерелә ап-ак өермәләр...
Хушлашабыз. Тагын каласың.
Күз алдыма килде шул күшеккән
Япа-ялгыз болан баласы.

Ак буранга кереп югалырмын.
Кул болгама, барыбер күренмәс,
Давыл барда әле чыдарсың да,
Ни кылырсың, ул да сүрелгәч.

Гел ак кына төс тә хафа салыр
(Ак урамнар, кырлар, түбәләр).
Туй күлмәген генә түгел, монда
Кәфенне дә актан тегәләр.

Гомер узган саен китә бара,
Бетә бара күңел тынгысы.
Һәр көрәшү — гүя тәү көрәшү,
Һәр аерылышу — гүя соңгысы.

Өерелә ап-ак өермәләр...
Хушлашабыз. Тагын каласың.
Сакла, язмыш.
Адаштыра күрмә
Шул күшеккән болан баласын...

Бел син, яме?

Алмаз **МОНАСЫЙПОВ** музыкасы. Рөстәм **ФӘЙЗУЛЛИН** сүзләре.

Лэйсәннәрдә кил син миңа,
Килмә син көзләремдә.
Кояш булып балкырга кил
Күк төсле күзләремдә!

Кушымта:
Бел син, яме, бел син, яме
Көнгә көн бәйләнәсен,
Алмагачның ал чәчәге
Алмага әйләнәсен.

Лэйсәннәрдә кил син миңа,
Килмә син көзләремдә.
Кояш булып балкырга кил
Күк төсле күзләремдә!

Кушымта:
Бел син, яме, бел син, яме
Көнгә көн бәйләнәсен,
Алмалар да алсуланып
Җирләргә тәгәрәсен.

Лэйсәннәрдә кил син миңа,
Килмә син көзләремдә.
Кояш булып балкырга кил
Күк төсле күзләремдә!


Кушымта:
Бел син, яме, бел син, яме
Көнгә көн бәйләнәсен,
Җиргә төшкән алмаларга
Ап-ак карлар явасын...





РАВИЛ МИРХӘЙДӘРОВ ПРОФЕССИЯСЕ БЕЛӘН ТӨЗҮЧЕ ИНЖЕНЕР. ТАШКЕНТТА ЯШИ ҺӘМ ШУНДАГЫ ТӨЗЕЛЕШ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ БЕРСЕНДӘ ӨЛКӘН ИНЖЕНЕР БУЛЫП ЭШЛИ.

РАВИЛ КҮБРӘК ҮЗЕНЕҢ ЯШЬТӘШЛӘРЕ, ЗАМАНДАШЛАРЫ ТУРЫНДА ЯЗА, ТАТАРСТАННАН ЧИТТӘ ЯШӘҮЧЕ ЯКТАШЛАРЫБЫЗ ТОРМЫШЫН ЯКТЫРТА, ТАРИХИ РЕВОЛЮЦИОН ТЕМАГА ДА МӨРӘҖӘГАТЬ ИТӘ. АНЫҢ ХИКӘЯЛӘРЕ ҮЗӘК МАТБУГАТТА ДА БАСЫЛЫП КИЛӘ. 1975 НЧЕ ЕЛНЫ ТАШКЕНТТА БЕРЕНЧЕ КИТАБЫ — ПОВЕСТЬ ҺӘМ ХИКӘЯЛӘР ҖЫЕНТЫГЫ БАСЫЛЫП ЧЫКТЫ. ЖУРНАЛНЫҢ БУ САНЫНДА УКУЧЫЛАРЫБЫЗГА РАВИЛНЕҢ «КЫЗЫЛЛАР» ДИГӘН ӘСӘРЕННӘН БЕР ӨЗЕК ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ.



Яшьләр иҗаты

Равил **МИРХӘЙДӘРОВ**

ҮЛ ЕЛЛАР

Ҡанәфер агачлары шау чәчәктә утырган май иртәсе иде. Заһит хәзрәт мәхәлләсендәге тын урамга, атларын ак күбеккә батырып, егерме кешедән торган казаклар отряды килеп керде. Мәчет янына җиткәч, чаптырып килгән атларын кырт кына туктаттылар. Ҡайсыдыр мылтыктан атып җибәрде. Мылтык тавышы, иртәнге тынлыкны ертып, аулак тыкрыклар, кәкре-бөкре урамнар буйлап адашып йөрде дә сүнде. Мәхәлләдә тагын тынлык — шомлы тынлык урнашты.

Ҡичәдән бирле йокы күрмичә, туктаусыз ат өстендә йөргән яшь хорунжийның йөзе агарынып, сулып калган. Ул баскан урынында тыпырдап торган алмачуарын да чак-чак кына тыя иде. Хорунжийның тизрәк җиргә төшәсе, оеган аякларын яздырасы килә. Ләкин ул халык белән нәселле чабыш аты өстennән, югарыдан торып сөйләшергә тели. Татарлар атны таный торган халык, алмачуарның да бәйгеләрдә дан казанган Абрек икәнен, әлбәттә, беләләрдер. Әйе, шулайдыр. Хорунжий бит аны шушы тирәләрдә кулга төшерде... Ләкин Оренбургка бу килүләре җиңел булмады. «Нинди асыл егетләр авып калды бит шәһәр итәгендә! Хәзер әнә, иясез этләр кебек, язгы туфракта аунап яталар. Күмәргә дә вакыт юк, ходаем, үзең кичер», — дип уйлап куйды хорунжий һәм шундук ак таштан салынган мәчет стенасындагы бизәкләрне карап маташучы, әле мыек та чыкмаган яшь бер егеткә кычкырды:

— Петро, шакы әле ишекне шәбрәк итеп... Мылтык түтәсе белән. Никтер озаклады бу мулла, әллә чукракланганмы? Ә сез, Матвей белән Гришка, барыгыз урамга, тәрәзә капкачларын шакып чыгыгыз. Күптән вакыт инде уянырга!...

Акрынлап халык җыела башлады. Шул чагында мәчет ишеге ачылып китте һәм аннан бөкрәеп, бөрешеп беткән бер карт чыкты. Өстендә чапан, башына яшел чалма ураган. Ул җыелган халыкка күз төшереп алды да, кулларын күтәреп, ашыкмыйча гына дога кылды, битен һәм сыек кына сакалын сыпырып куйды. Башкалар да шуны ук кабатладылар.

Йокысын чак кына җиңеп ат өстендә утырган хорунжий, башын күтәрә төшеп, хәзрәткә эндәште:

— Хәзрәт, без казаклар сотнясы... — Хорунжий беләзегенә камчы эленгән кулы белән читтәрәк торган казаклар төркемен ураткандай күңелсез генә ишарә ясап алды.— Генерал Дутов армиясеннән. Сезнең данлы шәһәрегезне кызыл шайтаннардан азат итеп йөрешебез. Югалтуларыбыз бик зур. Ләкин без тиздән мөселман динен дә, христиан динен дә хөрмәт итә торган власть урнаштырачакбыз. Ул сезгә сәүдә итү хокукын да кире кайтарачак. Шуңа күрә без сезгә ярдәм сорап мөрәҗәгать итәбез, үз иркегез белән безгә фураж, азык-төлек һәм атлар бирегез. Менә шушы өч олауны тиз генә төятегез дә без үз юлыбызда булырбыз. Югыйсә...— Ул сүзен әйтеп бетермәде. Югыйсә ни буласы инде болай да аңлашыла иде.

Хорунжий атыннан төшәргә җыенган гына иде, янына патша армиясе офицеры формасында (тик погоны гына юк) киенгән җайдак килеп туктады. Ул иелеп хорунжийга нидер әйтте. Соңгысы кабат тураеп утырды да дәвам итте:

— ... Тагын менә нәрсә: әгәр урамыгызда большевиклар, комсомоллар, активистлр булса, күрсәтегез, берьюлы исәп-хисапны өзеп китәрбез. Йөрмәсеннәр дөньяны болгатып...

Хорунжий атыннан сикереп төште. Аннары, тавышына мөмкин кадәр житдирәк, кырысрак төс бирергә тырышып: «Җә, бармы?!» — дип халык алдында әрле-бирле йөренергә тотынды.

Мулла турысына җиткәч, анысы:

— Бу урамда сәүдәгәрләр белән һөнәрчеләр генә яши. Алар диндар кешеләр, аллага ышаналар. Юк бездә большевиклар. Татарлар — эшчән халык, политикада гамьнәре юк, — диде.

— Анысы шулай аның, хәзрәт. Хәзер ул кызыл чума татарлар арасына гына түгел, без казаклар арасында да таралды. Шулай булгач, син, хәзрәт, ачуланма.

Әлеге сүзләреннән соң хорунжий, җилкәсендәге авыр йөкнең бер өлешен ташлап калдыргандай, теләр-теләмәс кенә погонсыз офицер янына атлады. Шул чагында аның каршысына ростовщик, мунча һәм алтын-көмеш кибете тотучы, татар бистәсендәге иң зур байларның берсе аксак Иса атылып чыкты. Чыкты да, хәйләкәр кысык күзләре белән әле офицерга, әле хорунжийга карап, тиз-тиз сөйләргә тотынды:

— Алдый ул хаҗи, алдый. Өч тапкыр хаҗга барган изге кеше булса да, ялган сөйли. Бар ул безнең урамда кызыллар, бар. Әле кемнәр диген! Эти-

ләре мәхәлләдә генә түгел, бөтен шәһәрдә хөрмәтле кеше, губернаторның үзе белән кул биреп күрешә. Ә балалары, тәмуг кисәүләре, белмим, кемгә охшаганнардыр? Күршеләре, ерак кардәшләре була торып, Иса абый, син инде кешеләрнең бурычларын үзең бәхиллә, янә власть халыкны таларга юл куймас, диләр бит. Таладыммыни мин? Тезләнеп сорадылар бит бурычка. Ҝибетләреңне, мунчаларыңны эшчеләр һәм крестьяннар дәүләте файдасына тартып алачаклар, диләр. Ә мин, гомер буе тир түгеп тырышкан кеше, аларның барысын да үзем тапмаган булып чыгаммы? Аллага шөкер, андый кара көннәрне күрергә насыйп булмады. Фетнә кузгатып йөргәннәре өчен, хәзер әнә дәүләт кешеләре алдында җавап бирсеннәр.

Офицер җәһәт кенә атыннан сикереп төште дә «Кайда алар?» — диде. Иса алтын балдаклар тезелгән кыска бармаклы симез кулы белән Сәфәр Тукаевларның юан-юан әрбет бүрәнәләрдән салынган ике катлы йортларына күрсәтте. Офицер белән хорунжий һәм бер-

ДА

ничә казак шундук әлеге йортка таба киттеләр. Аксак Иса алардан бераз арткарак калды һәм, елт итеп, халык арасына кереп югалды. Шул чагында кинәт мулла тавышы ишетелде:

— Иса, әгәр безнең урамда кеше каны коелса, инде күптәннән бирле өстеңдә асылынып торган адәм каргышына ходай каргышы да өстәләчәк. Мин сине алла исеменнән каргаячакмын. Моннан соң мәчет бусагасын атлап керәсе булма.

Шул сүзләренә салган ачуыннан хәлсезләнеп, карт хаҗи чайкалып китте...

Ҝазаклар мылтык түтәсе белән койманы шакый башладылар. Ишегалдында абалап этләр өрергә кереште. Озак та үтми, койма артында кемнеңдер авыр эшермә белән булышканы ишетелде. Этләр беразга тынып калдылар. Ҝапка ачылу белән, башта хорунжий, аның артыннан офицер һәм казаклар керде. Чылбырга бәйләнгән бозау кадәрле этләр, керүчеләргә таба ыргылып, юан тавыш белән кабат өрергә тотындылар. Чәчен шып-шома итеп китәргән, ап-ак эчке күлмәгенең ачык якасыннан йонлач күкрәге күренеп торган олы гәүдәле ир, этләрне чылбырларыннан тотып, баганага бәйләп куйды. Шуннан соң керүчеләргә таба борылган гына иде, каршысына унҗиде яшьләр тирәсендәге кыз бала йөгереп килде һәм аяк очына басып, ирнең җилкәсенә нафталин исе аңкып торган китель салды. Ир, кительны җайлабрак утыртырга теләп, җилкәсен селкетеп алды. Шул чагында тынып калган ишегалдында күкрәгенә рәттән тезелгән Георгиевский крестлары чыңгылдашып куйды. Ҝазаклар шәм кебек катып калдылар, мылтык түтәләре ташка төшеп бәрелде, әйтерсең лә кемдер «Ҝ ноге!» дигән команда биргән. Хорунжийның да кулы ирексездән папахасына күтәрелде. Офицер да аптырап калды. Һәм менә ул, капкага башын тыгып, урамга күз салды. Урам уртасыннан, титаклый-титаклый, ялгызы гына узып баручы ростовщикны күреп алды да ишегалдына чакырып кертте.

— Ялгышмадыңмы син, купец?— дип, офицер Исаны йорт хуҗасы каршына төрткәләп чыгарды. Чакырылмаган бу кунакларны тыныч кына күзәтеп торган олы гәүдәле күршесе белән ачулары кабарган казаклар арасында калгач, кылган эшләре өчен үкенүдән ахрысы, ростовщикның йөзе агарынып китте. Ләкин шундук чәрелдәп җибәрде:

— Үзе түгел, балалары, уллары кызыллар аның!

Өй тирәсенә халык җыела башлаган иде. Офицер капканы ябып куйды да:

— Әйдәгез, өйгә керик, без сезгә эш белән килдек,— диде.

Хуҗа борылып өйгә таба атлады. Аның артыннан, дагалы итекләре белән лап-лып басып, башкалар да иярделәр.

Буялган идәндә пычрак эз калдыра-



И. ӘХМӘДИЕВ рәсеме

калдыра казаклар өйалды аша иркен залга уздылар. Тышкы яктан тәрәзә капкачларын ачып куйдылар. Өйгә иртәнге кояш нурлары бөркелде. Казаклар, сокланып, түшәмдәге бизәкләрне, каймаларына алтын йөгертелгән хрусталь кандилны карарга керештеләр. Мичкә якынрак торганы чынаяк кирпечләрне капшап куйды.

Хорунжий, әйткәнне дә көтмичә, күн тышлы кәнәфигә барып чумды да, тузанлы итекләрен сузып, дәшми-тынмый җәелеп утыра бирде. Хорунжий да, башкалары да зурайтып стенага эленгән портретларны карый-карый зиннәтле зал буйлап йөргән офицерга текәлгәннәр иде. Офицер кинәт кенә борылып:

— Уларың кайда? — диде.

Ишек төбендә торган хуҗа тыныч кына җавап бирде:

— Исән булсалар, бүген төнлә отряд белән киткәннәр иде. Шәһәрне тотып тора алмадылар, бу юлы, күрәсең, зуррак көч туплап килгәнсездер.

— Әйе, көч җитәрлек, — диде офицер. — Ничек инде бу, агай, үзең Георгиевский крестның тулы кавалеры, шәһәрнең дәрәҗәле, хөрмәтле кешесе... Патша властеннан зарланырлык урының юк бит. Ә уларың кызыллар ягында?

— Мин, поручик әфәнде, бөтен гомерем буена җаным-тәнем белән Ватанга хезмәт иттем. Уларымны да балачакларыннан ук Ватанга тапшырдым. Реальный училище, гимназия... Ә икесе Казан университетын тәмамладылар. Икенче якка кушылганнар икән, димәк, аларга дөреслекнең кирәклесен өйрәтмәгән булганнардыр. Алар революциядән үзләре өчен ниндидер табыш эзләмиләр, ә халык өчен яңа тормыш төзүләренә, Ватанның данын элеккегә караганда да арттыруларына ышаналар. Укымышлы һәм халык яклы минем уларым. Ә халыкны мин хөкем итә алмыйм...

— Житте, картлач! — диде поручик, чәрелдәп.

— Коршунов! Ситников! Өйнең аскы катын, ишегалдын айкап чыгыгыз! Бәлки әле укымышлы большевиклар китеп өлгермәгәннәрдер?! Ә син, картлач, безне өске катка алып мен, бәлки без дә берәр нәрсә табарбыз.

Авыр итекләре белән дөбердәшеп, дүрт ир залның бер почмагына текә итеп ясалган бормалы баскычтан менә башладылар...

Бушап калган йокы һәм балалар бүлмәләрен караштыргалап байтак йөрделәр. Инде кире аскы катка төшәбез дип кенә торганда, поручик коридор түрендәге тагын бер ишекне күреп алды һәм аны аягы белән сак кына төртеп ачты.

Ике тәрәзәсе урамга караган кечерәк кенә бу бүлмә бик җыйнак һәм якты иде. Тәрәзә янында ук өстенә пөхтә итеп китаплар өелгән язу өстәле тора. Поручик һәйбәт итеп төпләнгән калын гына бер китапны алып карады да:

— Әлбәттә, шул, «Капитал!» — дип хорунжийга таба борылды.

Китапны кире куйганда пыялалы рамга куеп стенага эленгән бер фоторәсемгә... Ленин рәсеменә күзе төште. Ул аңа шундый якын, үрелсә, кулы җитәрлек иде. Поручик, корт чаккандай, стенадан читкә тайпылды һәм китап шкафы артында, күләгәдә торган нык саплы, бронза очлы Кызыл байракны күреп алды. Офицер ачуына буылып кычкырып җибәрде:

— Каштанов! Ал, ерт, яндыр!!!

Бая мәчет стенасындагы бизәкләрне карап торган яшь казак байракка таба атлады. Тик шундук егетнең юлын пәһлеван гәүдәле Сәфәр агай бүлде. Казак көч кулланмакчы иткән иде дә, хуҗа җиңелчә генә аның күкрәгенә төртеп алды. Петро урындыкларны аудара-аудара бер почмакка барып төште. Сәфәр агай байракны сөңге кебек итеп сабыннан тотып алды. Офицерлар алдында хәзер әйтерсең лә Алып батыр. Үзенең көчен бик яхшы белгән сугышчы басып тора иде.

— Җәгез әле, таегыз моннан, хәсрәт сугышчылар! Уларым булмәсе бу. Кагылмагыз шакшы кулларыгыз белән!

Шүрләп калган хорунжий, артына чигенә-чигенә, хуҗаны тынычландырырга тырыша иде:

— Тукта, агай... Тукта, гөнаһка тардырма...

Әмма хуҗа аларны байрак белән ишеккә таба кысрыклый бара иде. Шул чагында хорунжий артыннан ату тавышы ишетелде. Сәфәр агай кинәт туктап калды. Җилкәсеннән шуыша барган кителдәге Георгиевский крестлар кабат чыңылдашып алдылар. Ул да түгел, карт солдат бер генә адым атлады да идәнгә шуышып төшкән кителе өстенә йөзе белән гөрселдәп ауды. Поручик, аста калган байракны тартып чыгарырга теләп, хуҗа янына атылды. Ләкин Сәфәр агай уллары өчен иң кадерле бу нәрсәне әйтерсең лә үле килеш тә ятлар кулына бирергә теләми иде. Шуннан соң офицер ачуыннан маузерындагы барлык пуляларын да карт сугышчыга атып бетерде. Почмакта яткан яшь казак аткан саен сискәнеп, чукынып куя иде. «Ходаем, бу ни хәл бу... Георгиевский кавалерны соң...»

Ишегалдындагы кетәкләре өстендә утырган күгәрченнәр, ату тавышларыннан куркып, дәррәү куккә атылдылар һәм, үзләре артыннан күрше түбәләрдәге башка күгәрченнәрне дә ияртә-ияртә, биеккә, бик биеккә күтәрелделәр...

МӘХМҮД ГАЛӘҮНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ



(1887—1938)

Мәхмүд Галәү әдәби эшчәнлеген Бөек Октябрь революциясенә кадәр үк башлый.

Ул Арча районының Ташкичү авылында укытучы семьясында үсә, мәдрәсәдә укый, аннары Астраханьда укыту эшенә керешә. 1906 нчы елда ук большевикларның яшерен оешмасы эшендә актив катнаша башлый һәм революцион карашлары өчен мәктәптән сөрелә.

Аннары Оренбургка килеп типографиядә, китап кибетендә эшли, «Кармак» исемле көлке журнал чыгара. Аның беренче юмористик хикәяләре шул журналда чыга.

Октябрь революциясе язучының иҗатына һәм иҗтимагый эшчәнлегенә киң юл ача. Ул Башкортстанда — халык мәгарифе өлкәсендә, соңрак Мәскәүдә, СССР халыкларының Үзәк нәшриятында җаваплы эшләр башкара. Аның иҗаты чәчәк ату шушы елларга туры килә, ул танылган рус язучыларының күп кенә әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә.

Мәхмүд Галәү пьесалар, романнар, күп санлы хикәяләр яза. Аның «Канлы тамгалар» дилогиясе — «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» исемле романнары татар әдәбиятының алтын фондына керде, русчага тәрҗемә ителеп, берничә тапкыр басылып чыкты.

Бу киң колачлы әсәрләрдә язучы узган гасыр ахырында авылларда халыкның сыйнфый катламнарга аерылуын, ярлы крестьяннарның рухи үсешен зур осталык белән күрсәтә.

Дилогиянең икенче өлеше булган «Мөһаҗирләр» романында революция алдыннан татар авылларында барган катлаулы социаль вакыйгалар аеруча ачык тасвирлана. Анда дин әһелләренең һәм милләтчеләрнең коткысына бирелеп Төркиягә күчеп киткән кешеләрнең аяныч язмышы да зур урын ала. Бу яктан роман Габдулла Тукайның «Китмибез!» шигыре белән аваздаш.

Мәхмүд Галәү романнары бүгенге көн укучысын да дулкынландыралар һәм безне ил язмышы, халык язмышы турында тирән уйланырга мәҗбүр итәләр, узган чорны ачык итеп күз алдына китерергә мөмкинлек бирәләр.

Бу җырлар күпсанлы укучыларыбызның теләгән үтәү йөзеннән бирелә.



ИНТЕРНАЦИОНАЛ

Русчадан Нәкый ИСӘНБӘТ, Әхмәт ИСХАК, Нури АРСЛАНОВ тәрҗемәсе

Кузгал, уян, ләгънәт ителгән
Коллар һәм ачлар дөньясы!
Кайный ачу белән безнең кан,
Соңгы сугышка ул ярсый.
Коллык дөньясын җимерербез,
Тамырыннан йолкып алып.
Яңа, иркен дөнья төзербез,
Хуҗа булыр аңа халык.
Кушымта:
Бу безнең иң ахыргы,
Иң каты зур сугыш. (2 кат.)
Интернационал белән
Балкыр яңа тормыш.
Алла да, патша да, батыр да
Азат итмәс беркем безне.
Яулап тик без көрәш сафында
Алырбыз үз иркебезне.
Җимерик дисәң коллык, җәберне,
Яулыйк дисәң син барын да,
Дөрләт утны, тизрәк тимерне
Сугып кал кызу чагында!
Кушымта.
Бөтен дөнья эшче халкы без,
Бөек хезмәт армиясе,
Тик без бөтен җиргә хаклыбыз,
Ә паразитлар — һичкайсы!
Күкрәр күкләр, яшен сугар да,
Тар-мар итәр этләр явын,
Безгә шунда кояш чыгар да,
Чәчеп торыр үз нурларын.
Кушымта.
Бу безнең иң ахыргы,
Иң каты зур сугыш. (2 кат.)
Интернационал белән
Балкыр яңа тормыш.

ВАРШАВЯНКА

Русчадан Әхмәт ФӘЙЗИ тәрҗемәсе

Шомлы җилләр исәләр өстебезгә,
Үч тойгысы йөрәкне җилкетә.
Канлы сугыш ачтык без дошманнарга,
Билгесез язмышлар безне көтә.
Тик без горур, кыю кузгалырбыз,
Эшче байрагын без кулга алырбыз.
Бар халыкларның азатлык байрагын,
Якты тормыш, данлы, шатлык байрагын.
Кушымта:
Әйдә, эшчеләр,
Изге яуларга, (2 кат.)
Марш, марш алга,
Ирек дауларга.
Эшче үлә меңәрләп ач тормыштан,
Дәшми калу мөмкинме, туганнар!
Безнең юлдашларның яшь йөрәкләрен
Куркыта алырмы төрмә белән дар?
Зур сугышларда эзсез югалмаслар
Ил хакына егылган батырлар.
Алар яшәрләр җиңү байрагында,
Исемнәре җырларда яңгырар.
Кушымта.
Тик изелгән халыклар безнең дуслар,
Дошманга үч ялкыны кабына,
Халык каны чәчрәгән тәхетләрне
Без буярбыз дошманнар канына.
Иң аяусыз үч алынсын дошманнан,
Хезмәт халкын имүче еланнан,
Безнең ачу яндырсын тәхетләрне,
Якын җиңү сәгате, туганнар!
Кушымта:
Әйдә, эшчеләр,
Изге яуларга, (2 кат.)
Марш, марш алга,
Ирек дауларга!

КОМ БУРАНЫ

Татар халык җыры

Ком бураны туздырабыз
Урамнардан узабыз, (2 кат.)

Ай узабыз, ел узабыз,
Якты юллар сызабыз. (2 кат.)

Ком бураны басыладыр,
Давыл тынгач, кич булгач, (2 кат.)

Без давылдан
курыкмыйбыз, (2 кат.)
Үзебез давылдай булгач.

Ком бураны каты була,
Каты булса җил көче, (2 кат.)

Без бураннар туздырабыз,
Көрәшкәндә ил өчен. (2 кат.)

КӨЗГЕ АЧЫ ҖИЛЛӘРДӘ

Татар халык җыры

Бардым күлгә, салдым
кармак,
Безгә балык эләкми шул.

Кушымта.

Йөгереп китәрдәй булам,
Кайтып җитәрдәй
булам,
Көзге ачы җилләрдә лә
Туган-үскән илләргә.

Бетсен патша, янсын тәхет,
Безгә сугыш кирәкми шул.

Кушымта.

Без утырган машинаның
Тоткалары җиз генә шул.

Кушымта.

Бер илләрдән чыгып
киткәч,
Кайтып булмый тиз генә
шул.

Кушымта.

АЙ, ДУСЛАР!

Татар халык җыры

Алга дибез, алга атлыйбыз,
Алга таба барабыз.
Алга барырга кушкан бит
Безгә Ленин бабабыз.
Алга барырга кушкан бит
Безгә Ленин бабабыз.

Ай, дуслар,
Нурлар алыйк,
Юллар салыйк,
Гөлләр кадыйк маякка,
Гөлләр кадыйк маякка!

Алсу нурлы таңнар атты
Безнең зур илебездә.
Бөек Ленин күрсәтте бит
Туры, якты юл безгә.
Бөек Ленин күрсәтте бит
Туры, якты юл безгә.

Ай, дуслар,
Нурлар алыйк,
Юллар салыйк,
Гөлләр кадыйк маякка,
Гөлләр кадыйк маякка!

АККОШ

Халык көе, Әхмәт Фәйзи сүзләре

Аккош йөзә,
Дәрья гизә,
Дулкынлатып шәүләсен; (2 кат.)

Дошманнарның күле
кипсен,
Безнең диңгез шауласын. (2 кат.)

Аккош оча,
Йолдыз коча,
Киңлекләргә туймыйча; (2 кат.)

Без тынмабыз
Дошманнарның
Исмен җирдән җуймыйча. (2 кат.)

Аккош очар
Ил буйлап,
Шаулап искән җил булып; (2 кат.)

Без яшәгәндә
Ил булып,
Дошман очар көл булып. (2 кат.)

МАКТАУГА ЛАЕКЛЫЛАР



Римма ЯОСЫПОВА, Октябрь Революциясе ордены кавалеры, Зеленодольск районы, Яңа Җәке мәктәбе укытучысы.

«Аврора» залплары яңгыраганда әнием әле сабый гына булган. Заманына күрә укымышлы саналган, Зеленодольск районының Уразлы авылы мәктәбенә нигез салышкан бабам кызының башыннан сыйпап шуны әйткән:

— Яңа заманга чыктык. Бәхетле бала икәнсең. Хәзер шуңа лаеклы булып үсәргә кирәк.
«Әдәмне алга илткән уку,
Укып күккә җиткән уку,
Уку-уку, уку-уку», —
дигән шагыйрь. Хәзер син мөгълүмат алырга, алган белемеңне башкалар белән уртаклашырга тиешсең.

Бабай сүзен тоткан әнием. Совет мәктәбенең беренче карлыгачларыннан саналган, тормыш иптәшен дә укытучылар арасыннан сайлаган. Бүгенге көндә Уразлы авылы хезмәт ияләренең яртысы әтием-әнием шәкертләре, безнең укучыларыбыз, дисәм, һич ялгышмам.

Әтиемне Бөек Ватан сугышына Октябрьның 24 еллыгын тантана иткән көнне бөтен мәктәп белән озаттык. Бүгенгедәй хәтеремдә, «Тырышып укыгыз, балалар, — диде ул, — фронттагы әтиләрегез сезнең белән горурланырлык булсын. Дошманны җиңәрбез. Октябрь казанышларын бездән беркем дә тартып ала алмаячак».

Әтинең сүзләре расланды, тик үзе генә әйләнеп кайтмады. Аның урынына шәкертләре басты. Әнием — Татарстанның атказанган укытучысы Хәнифә Фәхретдинова — 38 ел буена шул Уразлы мәктәбендә укытып ялга китте. Аңа алмашка кызлары — сеңелем Роза белән мин, укып, укытучылар булдык. Менә 24 ел инде рәттән башта шул Уразлы мәктәбендә, хәзер Яңа Җәке сигезьеллык мәктәбендә балаларга рус теле укытам. Пионер галстугы таккан кызым Гөлшат та инде иптәш кызларын каршысына утыртып укытучы булып уйный башлады. Аның хыялы да бабасы, әбисе, әнисе, апалары традициясен дәвам иттерү.

Совет укытучысы! Дәрәҗәле, мактаулы профессия. Бәхетле балачак мәктәптә дәвам итә. Укытучы әнә шул сабыйларны җитәкләп гаҗәп күркәм, якты дөньяга алып керә. Укучы укытучысы аша, ул укырга өйрәткән китаплар аша үсеп кеше була, тормышка путевка ала, хезмәт герое була, ачыш ясый, китап яза. Әнә шундый җаваплы һәм данлы профессиягә ия булуым өчен мин шат һәм бәхетле.



Мәрзия ЗАҺИРОВА, Октябрь Революциясе ордены кавалеры, Арча районы, Камил Якуб исемендәге колхозның сарык караучысы.

һәркем ирекле хезмәт итә ала торган илдә яшәмәсәм, язмышым ни белән чикләнгән булыр иде, аныын күз алдына китерүе кыен. Чөнки авыр сугыш елларында әнием 6 бала белән тол калды. Иң олысы мин идем. Шул еллардан башлап колхозда бригадир булып эшләдем. Туганнарымны үстерештем.

Тормышка чыккач үземнең өч балам булды. Аларны да әтисез үстерергә туры килде. Бер дә әтиле балалардан ким итеп үстермәдем. Шуның өстенә әле кайнанамны, иремнең авыру апасын тәрбияләдем. Менә күрәсез, тормыш ачысын да шактый татырга туры килде. Шулай да мин үземне бәхетсез санамыйм. Гомерем буе хезмәтемнән ямь табып яшим. Менә 15 ел инде фермада сарыклар карыйм.

Мин эшли башлаганда сарыкчылык колхозның артта калган бер тармагы иде. Ул хәлдән чыгу өчен ферма коллективы зур тырышлык куйды. Алдынгылар тәҗрибәсенә таяндык, сарыкларның нәселен яхшырту юнәлешендә күп эшләдек. Хәзер бездә нечкә йонлы меринос нәселле сарыклар гына асрала. Районда, республикада гына түгел, бөтен ил күләмендә макталырлык нәтиҗәләргә ирештек. 1973 елгы эш нәтиҗәләре белән Мәскәүдә Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә катнашып, көмеш медаль алдым. Шул ук елны мине хөкүмәтебез «Почет билгесе» ордены белән бүләкләде.

Узган елны да яхшы нәтиҗәләр белән төгәлләдек. Сарыкчылыктан колхоз кассасына 15 мең сумнан артык чиста табыш керде. Колхоз буенча һәр сарыктан уртача 4 кг 920 г йон, 100 ана сарыктан 138 бәрән алынды. Мин социалистик ярышта җиңүче булдым. һәр сарыктан 6 кг 130 г йон кырыктым, 100 ана сарыктан 139 бәрән алып үстердем.

Бөек Октябрьның 60 еллыгын безнең ферма коллективы яңа хезмәт җиңүләре белән каршылады.

1976 елда хөкүмәтебез мине Октябрь Революциясе ордены белән бүләкләде. Хезмәтем миңа бәхет, хөрмәт китерде. Колхоздашларым мине почетлы колхозчы иттеләр. Авылдашларым берничә тапкыр авыл Советына депутат итеп сайладылар. Менә 7—8 ел буена коммунистлар, зур ышаныч белдереп, мине партбюрога сайлап киләләр. Күрәсез, производствода гына түгел, совет һәм партия эшендә дә катнашып киләм. Болар бер үз тырышлыгым белән генә ирешелгән уңышлар түгел, әлбәттә. Барысы өчен хөкүмәтебезгә һәм барлык хезмәттәшләремә рәхмәт әйтәсем килә.

Гаиләдә АТАНЫҢ РОЛЕ

«... С-с-с, әтиегез йоклый, әкренрәк...», «Сабыр ит, башта табынга әтиең утырсын», «Башта әтиең белән киңәшик». Я, мондый искәрмәләрне кайсы гына гаиләдә ишеткәнебез юк икән. Борынгыдан калган бик күпләргә таныш бер кагыйдә бар: ата кеше йорт хуҗасы, аңа буйсынырга, аның дәрәҗәсен сакларга, аннан узып эш йөртмәскә, аның сүзе — закон!

Ул заманда хатын-кыз өйдә бала багып, ир тапканны аш итеп торудан гайре эш башкара алмаган. Укый-яза белмәгән, базар күрмәгән, ил гизмәгән, шәригать тарафыннан да, закон тарафыннан да кимсетелгән бу җенес турында төрле мәкальләр туган: «Тавык кош түгел, хатын кеше түгел», «Хатын-кызның чәче озын, акылы кыска», янәсе. Әйтергә кирәк, иске заман калдыгы саналган бу күренешләр, бу әйтемнәр капиталистик илләрдә әле һаман да үз көчендә. Производствода башлыча ирләр эшли, хезмәт хаклары ирләргә караганда хатын-кызларга икеләтә-өчләтә кимрәк түләнә.

Ә бездә, Октябрь казанышлары нәтиҗәсендә ирешелгән тигез хокуклылык ирләр белән хатыннар арасындагы бу киртәне юк итте, хатыннарны ирләр белән бер дәрәҗәгә бастырды. Без, хатын-кызлар, моны бик яхшы тоябыз, ирләр белән бер сафта атлыйбыз, бер үк эшләрне башкарабыз, гаиләбез алдында да ихтирамыбыз зур. Ләкин шуны да онытмыйк, кыз бала нинди генә уку йорты тәмамламасын, никадәр генә уңган, кыю, талантлы, горур булмасын, ул барыбер кияүгә чыгып хатын кеше, әни кеше буласы. Аны, шагыйрьләр теле белән әйткәндә, кешелекнең гүзәл яртысы, диләр. Ул тормышта үзенең яклаучысы — ире, балаларының әтисе барлыгын тоеп, уттан, судан аның җилкәсенә ышыкланып яши, шулай булырга тиеш тә. Рус язучысы һәм тарихчы Н. М. Карамзин «Бернинди мәктәп тә, институт та, пансионат та яхшы ата биргән тәрбияне бирә алмый», ди. Димәк, кыз бала үзе дә гаиләдә дәрәҗә тоткан әнә шундый яхшы атадан тәрбия алган булырга тиеш. Андый аталар, андый ирләр күп безнең һәм, әйтергә кирәк, алар корган гаиләләр иң бәхетле гаиләләр санала. Алар бик урынлы рәвештә гаилә башлыгы булып торалар, аларның киңәше белән башкарган эш таркалмый, алар ихтирамга да лаеклылар. Бу хатын-кызларның гаиләдә тоткан ролен киметми, хокукларын кимсетми, киресенчә, алар тормыш баскычларыннан иңне иңгә куеп, киңәшеп, үз бәхетләре өчен бергәләп көрәшеп атлыйлар. Ләкин, кызганычка каршы, ирләрнең кайберләре арасында үз бәясен төшереп, гаиләдә дәрәҗә казанмаганнары да бар. Боларга рухи яктан көчсез, вак җанлы, хатын-кыз җилкәсенә салынып яшәргә теләгән ялкау табигатьле һәм үз ихтыярына баш була алмый эчүчелеккә бирелгән ирләр керә. Андыйлар — гаилә өчен генә түгел, җәмәгатьчелек өчен дә йок саналган мәхлук кешеләр. Гаиләдә, әлбәттә, мондый типтагы ирләр яки аталар ихтирам казана алмыйлар, күпчелек очракта тормыш йөген хатын тартып бара. Монысы һәркемгә ачык һәм таныш. Сүз алар турында түгел, ә уңай атмосферада туган, тигез канат булып яшәгән, тормыш итә белә торган ир булган гаиләләрдәге ата кешенең роле турында бара. Сирәк кенә булса да мондый гаиләләрдә дә низагълар чыгып торгалый. Асылда, арада өстенлекне бүлешү бара. Кем өйдә хуҗа! Синме, минме! Ирнең ир буласы килә. Ә хатын аңа үзеннән узарга ирек бирми. «Белемебез тигез, бер үк эшне башкарабыз», ди ул. Арада хезмәт хакының иреннән артыклыгы белән мактанучылары да очраштыргалый. Һәр икесе дә уртага утырып үзара матур гына хәл ителәсе мәсьәләләрдә бәхәс куба. Моның шаһитлары, әлбәттә, балалар була. Кыз бала бу тамашаны күреп, үзенең «артык» өстенлеген тоеп, корасы гаиләсе өчен «үрнәк» алып үсә. Ә ир балада әтисе өчен кимсенү уяна, ирлек горурлыгы кими. Кыскасы, аларның күз алдында ата дәрәҗәсе кими. Ә атаның гаиләдә тоткан үз роле булырга тиеш. Әни кеше балада нәфислек, тырышлык, күркәм холык тәрбияләсә, ата кеше көчле ихтыяр, кыюлык, фидакарьлек тәрбияләргә тиеш, дип карый һәм дөрес уйлый. Ә моның өчен әти кеше үзе әнә шундый сыйфатларга ия булырга, ягъни әти кеше үз урынында булырга тиеш.

Акыллы, һәрчак аек, кешелекле ата бала өчен тере үрнәк. Гадәттә, хатын-кызның ир-атка караганда бала тәрбияләргә вакыты аз кала. Ул көндезен эштә, кичен кайткач кухняда: пешерә, юа. Йорт эшләренә теләп булыша торган ярдәмчел ир-атлар да бала янында күбрәк булалар һәм аларның тәрбияви тәэсирләре дә көчлерәк. Ләкин күпләр, хәтта менә дигән аталар да балалары алдында артык катгый, аз сүзле, хәтәр җитди булып кыланырга һәм шул юл белән үз дәрәҗәләрен күрсәтергә тырышалар, — дип язган В. Г. Белинский, — ә мондый балалар аталарын чын ихтирам белән түгел, ә куркып кына «зурлаганга» сабыша. Ә бу кешедә «икейөзлелек тәрбияли».

Әти кешенең «гаиләдә өстенлек күрсәтәм» дигән мондый тәкәбберлелеген инкарь итүче мисаллар бик күп. А. П. Чеховның «Өйдә» дигән бик шәп хикәясе бар. Җитди кыяфәтле, кырыс холыклы прокурор Быковский котын алырдай хәбәр ишетә. Җиде яшьлек малае тәмәке суыра башлаган. Я, малайны ничек кенә бәладан коткарырга!! Бу — җинаятьче, яки үзенең укучысы булса прокурор мәсьәләне бик җиңел хәл итәр иде, ә бит бу «гаепле» кеше, аның өзелеп яраткан улы. Ул аңа тәмәкенең зарары турында аңлатырга уйлый, ләкин моннан бернинди нәтиҗә чыкмасына ышана. Чөнки балаң синең яратуыңа таяна, нинди генә гаеп эшләсә дә гафу итәчәгеңне тоеп тора. Шунда прокурор улына бер әкият сөйли: «Бер карт патшаның синең кебек бердәнбер малае булган. Әйбәт малай булган ул. Әтисенең сүзен тыңлаган, вакытында йокларга яткан, шаярмаган, шауламаган. Тик ул тәмәкече булган. Шуның аркасында гел авырган, зәгыйфьләнгән һәм егерме яшендә чирләп үлгән. Әлеге бернинди таянычсыз, ярдәмчесез ялгызы калган карт атаны дошманнары бөлдереп, үтереп киткәннәр. Менә шулай, балакай...»

Прокурорның улы шул чак тәрәзәгә карап уйланып торган да әтисен кочаклап алган һәм колагына «Мин моннан соң беркайчан да тәмәке тартмаячакмын», дигән.

Дөрес, әтиләр төрле булалар. Әмма аларның төп максаты — балаларын киләчәккә лаеклы, тәртипле, тырыш итеп үстерү. Ата кеше моңа ирешү өчен үзе үрнәк булырга, улы-кызы алдында дәрәҗәсен сакларга һәм, барыннан да бигрәк, яхшы тәрбияче булырга тиеш.

Әминә ХАЛИКОВА,
Татарстанның атказанган укытучысы.



Хәрәкәт көч бирә

Хәзерге заман кешесенең тормыш-көнкүреше һәм хезмәте рухи һәм психик көчне аерата күп сорый. Чөнки фән һәм техника үсеше, производствоның камилләшүе, табигый рәвештә, кешене физик хәрәкәтләрдән азат итә. Бу хәлне замана үзе китереп чыгара. Шуңа күрә саулыкны, тәннең җиңеллеген, буй-сынның зифалыгын саклау өчен, кешегә физик күнегүләр ясарга, спорт белән шөгыльләнергә кирәк.

Билгеле булганча, үзәк нерв системасы бөтен әгъзага җитәкчелек итә, аларга үзенең «әмерен» биреп тора. Бер үк вакытта үзәк нерв системасы әгъзалардан туктаусыз «хәбәрләр» алып, үзе дә активлаша. Аз хәрәкәтләнгәндә үзәк нерв системасына сигналлар — «хәбәрләр» җитәрлек килми, мускулларда торгынлык барлыкка килә. Бу хәл озакка сузылса, кайбер әгъзаларның зәгыйфьләнүенә китерә. Бу инде, бер яктан, сәламәтлеккә зарарлы булса, икенчедән, гомер озынлыгына да үзенең йогынтысын ясый.

Физик хезмәт тән тазалыгына гына түгел, акыл үсешенә дә уңай тәэсир итә. Физик тәрбия хакында борынгы грек, кытай, гарәп медиклары гыйльми хезмәтләр язганнар, бу чараны дәвалау процессына керткәннәр. Рим врачы Гален, физик күнегүләр белән меңләгән авырулардан савыгып була, дип язган. Физик күнегүләрне белеп кулланганда, кеше гармоник камиллеккә ирешә, гәүдәсендә җиңеллек тоя, аның буй-сыны зифа була. Гимнастика, җәяү йөрү, төрле уеннар, су коену, кояшта кызыну, диета саклау, музыка һәм декламация кебек чаралар актив ял бирәләр.

Актив хәрәкәтнең сәламәтлеккә файдасы хакында сүз барганда, моны рекордлар куярга өндәү дип карарга ярамый. Әйтик, чаңгыда, тимераякта шуу, велосипедта йөрү, йөзү, ниһаять, җәяү йөрү — болар һәркемнең кулыннан килә торган, күңелне күтәрә торган шөгыль.

Бик күренекле кешеләрнең күркәм сыйфатларының берсе — хәрәкәтчәнлек. Бөек рус шагыйре А. С. Пушкинның физкультураны яратуын замандашлары шаккатып сөйләгәннәр. Киң җилкәле, тоз гәүдәле, күзәтүчән һәм һәрчак үткер карашлы, җитез хәрәкәтле шагыйрь суда тиз йөзә алган, пистолеттан оста ата белгән, атта йөргән, кышын тимераякта шуган, фехтование белән шөгыльләнгән.

Бүгенге көндә хәрәкәтнең тылсымлы сере фәнни тирәнлектә ачыкланды. Кәеф



Авылда көзнең аеруча бер күңелле чоры була. Ул — сугым вакыты, өйләрдә гөрләп каз өмәләре үткән чак. Гадәттә шушы чорда ешрак пешерелә торган кайбер ризыклар турында язарга булдык.

ШУЛПАЛЫ КАЗ БӘЛЕШЕ

Симез каз итен сөяге белән бергә 15—20 граммлы кисәкләргә турыйлар. Аңа әрчеп туралган бәрәңге, суган кушыла, борыч һәм тоз сибеп болгатыла.

Шулпалы бәлеш төче камырдан ясала.

Камыр басу өчен сөткә йомырка сытып туглыйлар. Шуңа он салып, токмач камырыннан йомшаграк итеп камыр басалар. Камырны, берсен дүрттән өч өлеш, икенчесен дүрттән бер өлеш итеп, ике кисәккә бүләләр. Зуррак кисәкне 5—6 миллиметр калынлыгында, читләре табадан кул яссуы чыгып торырлык итеп, түгәрәкләп җәяләр, майланган табага тигез итеп салалар. Камыр өстенә әзер эчлекне өеп салалар, камырның кырыен күтәреп бөгеп чыгалар. Камырның калган кисәген җәеп, бөгелгән бәлешкә каплыйлар да чеметеп ябыштыралар. Бәлеш капкачының уртасына тишек тишелә һәм аңа камырдан бөке ясап каплана. Бәлешне, өстен майлап, мичкә куялар. Мич кызу булып бәлешнең тышы катып китмәсен өчен, 30—40 минуттан соң өстенә суга манчылган кәгазь каплыйлар. Бәлеш мичтә 1—1,5 сәгать торгач, аңа каз шулпасы салалар һәм яңадан мичкә тыгалар.

Бәлешне табынга чыгарыр алдыннан аңа тагын шулпа салалар, табасы белән табынга куялар. Башта капкачын кисеп, өлешләп бүләләр, аннан һәр тәлинкәгә эче салына, соңыннан кырые, төбе киселә.

Бер бәлешкә: 1,5—2 кг камыр, 1,5—2 кг каз ите, 1,5—2 кг бәрәңге, 200 г суган, кирәк кадәр борыч, тоз, ике стакан шулпа кирәк.

КАЗ БАШ-АЯГЫННАН БӘЛЕШ

Бәлешнең эчлеге болай әзерләнә. Каз башы яхшылап йолкына, өтелә. Телен калдырып, томшыгы кисеп алына, башы аскы яктан ярыла, кайнар суда пешекләнә. Авыз эчендәге лайлалы катлау һәм теленең тиресе кубарып алына, тагын бер кат салкын суда юыла.

Каз аякларын сүрән генә утка куеп алалар. Аларның тиресе куыкланып кабара һәм бик тиз кубарыла. Тиресе кубарылган аякларны юарга, тырнакларын кисеп ташларга кирәк. Казның баш-аяклары, канатлары шактый эре итеп турала.

Туралган баш-аякка чистартып туралган бәрәңге, суган кушыла, тоз, борыч сибеп бәлеш ясала. Калганы барысы да ит бәлеше пешергәндәгечә эшләнә.

ҮПКӘ-БАВЫР ТУТЫРМАСЫ

Тутырма тутыру өчен мөгезле эре терлек һәм кәҗә, сарык эчәкләре файдаланыла. Шулай да тутыру өчен сыер эчәгесе яхшырак. Диаметры 2—3 сантиметрлы эчәкләрне алып, өйләндерә-өйләндерә салкын суда кат-кат юарга, лайлаларын пычак белән кырып, бик яхшылап чайкарга да, чистартып бетергәч, бер башын җеп белән бәйләп, эчәкнең икенче ягын өйләндерергә кирәк. Шуннан соң эчәккә әзерләнгән эчлекне тутыралар.

Яңа гына суелган терлекнең үпкә-бавыры, йөрәге яхшылап юыла, элпәләреннән, тамырларыннан чистартылып вак кына итеп турала. Аны суган белән бергә иттарткычтан үткәрәләр яки чапкы белән чабалар. Кирәгенчә тоз, борыч сибелә, йомырка сытып болгатыла. Сөт яки салкын шулпа салып сыеклаталар да, шуңа дөге яки карабодай ярмасы кушып эчәккә тутырыла. Тутырманың эчлеге сыек булырга тиеш. Пешергәндә эчәк шартламасын өчен өчтән ике өлешенә генә эчлек тутырыла. Шуннан эчәкнең икенче очын да бәйләп шулпага салып пешерәләр.

Моның өчен: 1 кг үпкәбавыр, 100 г дөге яки 120 г карабодай ярмасы, 1 йомырка, 100—150 г суган, кирәгенчә тоз, борыч, 300—400 г сөт яки шулпа алына.

АТ КАРТАСЫ

Аны атның түгәрәк картасыннан әзерлиләр.

Юан картаны әйбәтләп юып чистарткач, түгәрәк килеш (ярмыйча) 25—30 см озынлыгында кисәкләргә турыйлар. Кечкенә уклау яки бармак белән һәр кисәкнең эчке ягы кайтарылып өйләндерелә, ягъни майлы тышы эчтә калдырыла. Шуннан соң аны кайнап торган суга салып, биш-алты минут пешеклиләр. Аннары картаны судан алып бераз суыталар.

Шулай пешекләнгән картаны куна тактасына салып, өске катлавын пычак белән юка гына итеп кырып алалар. Аннары тагын бер кат җылымса суда юалар, карта күмелерлек кенә тозлы су салып, ике сәгать чамасы пешерәләр. Эчендәге мае пешкән чакта эреп суга чыкмасын өчен, картаның ике башы да кысып бәйләп куела.

Картаны салкын килеш, калҗалап турап, горчица яки кәрән белән табынга куялар.

ЭЧӘК-КАРЫН СУМСАСЫ

Яңа суйган терлекнең эчәкләрен һәм карынын

күтәренкелегенә, тәндә көч артуга, җиңеллек тоюга ирешү өчен, берничә көнлек физик күнегүләр ясау гына җитми, моның өчен гомер буе хәрәкәт яратырга кирәк. Фәнни күзәтүләрдә менә мондый кызыклы фактлар ачыкланды. Баш авыртудан, йөрәк тотудан, сулыш кысудан зарланган өлкән яшьтәге кешеләргә җәяү йөрү, физик күнегүләр белән дәвалану зур файда бирә.

Озак хәрәкәтләнми тору организмда тискәре үзгәрешләр барлыкка китерә. Галимнәр моны да тәҗрибәләрдә ачыклаганнар. Мәсәлән, ун айлык күселәр аз хәрәкәтләнү шартларына урнаштырылгач та 80—85 көннән соң үләләр. Ә табигый шартларда алар 600 көн яши.

Актив хәрәкәт җитмәү аркасында организмда төрле кимчелекләр барлыкка килүе мөмкин. Әйтик, аз хәрәкәтләнгән яки йөрүне сангa сукмаган кешеләр гадәттә төрле йогышлы авыруларга тизрәк бирешәләр. Атеросклероз, гипертония, миокардо инфаркты кебек авырулар да аз хәрәкәтләнүче кешеләрне сагалап кына тора.

Тарихи хроникалар күрсәткәнчә, моннан 100 ел элек кешелек өчен кирәк булган эшләрнең 4 процентын гына машиналар башкарган булса, бүгенге көндә әлеге сан 99 процентка җиткән. Бу хәл бүген физик культураның, хәрәкәтнең көндәлек тормышка кертелергә тиешлеген күрсәтә. Әлбәттә, физик культураны физик эш белән бутарга ярамый. Чөнки физик эш вакытында бары аерым мускулларның гына активлыгы артырга мөмкин, ә физик культура күнегүләрен ясаганда тәндәге барлык әгъзалар да, бер-беренә бәйле рәвештә, актив хәлгә киләләр. Шуңа күрә физкультура белән шөгыльләнү һәркем өчен мөһим.

Кеше, үзенең мөмкинлеген исәпләп, гомер буе физкультура белән шөгыльләнергә, күбрәк хәрәкәтләнергә тиеш. Моның өчен безнең карамакта парклар, спорт заллары, үзебезне чорнап алган табигать мохиты бар. Даими рәвештә хәрәкәтләнәбез, физкультура белән шөгыльләнәбез икән, димәк, аңлы рәвештә тәндәге матдәләр алмашын үстерәбез, кан тамырларының эластиклыгын, функциональ мөмкинлеген арттырабыз. Артык симерүгә юлыккан кеше дә хәрәкәттән, физкультура күнегүләреннән ярдәм табар, үзенең нормаль авырлыгына кире кайтыр. Хәрәкәтнең йогынтысы нерв системасында, йөрәк эшчәнлегендә, сулыш алуда, ашказаны тазалыгында чагылмый калмас. Физик эш, актив хәрәкәт башкаргач, аппетит яхшыруын, ризык тәмлерәк булуын кем генә татымый икән. Даими рәвештә физик күнегүләр белән шөгыльләнгән кешеләрнең рухы күтәренке, гәүдәсе җыйнак һәм җиңел була. Андый кешеләргә сокланып карыйсың һәм «хәрәкәттә — бәрәкәт» дигәннәренә кабат ышанасың.

Дания ВӘЛИМӨХӘММӘТОВА,
медицина фәннәре докторы, профессор.
Нәкыйп КАШТАНОВ,
врач.

пычак белән ярала̄р, салкын суда берничә кат яхшылап юалар һәм кайнар су белән ныклап пешеклиләр. Шуннан соң аларны пычак белән кырып салкын суда тагын бер кат юалар. Болай эшкәртелгән эчәк һәм карын 1—2 көн салкында тотыла.

Сумса ясау өчен эшкәртелгән эчәкне вак кына итеп турыйлар, суган белән бергә иттарткычтан үткәрәләр, борыч, тоз сибеп болгаталар, өчы камырга кыстырып сумса ясыйлар, табага яки калайга тезеп мичкә куеп пешерәләр.

Бер сумсага: 40—50 г камыр, 30—40 г тартылган эчәк-карын, 20 г суган, кирәк кадәр тоз һәм борыч, сумсаны пешкәч майлау өчен 3—4 г май алына.



КӘБЕСТӘ ХИКМӘТЛӘРЕ

Кәбестәне бөтен килеш тозлаганда, арасына вакланган кукуруз орлыклары салсаң, ул төмле дә, нык та була.

• • •

Тозлы кәбестәне 1—4 градус җылылыкта саклау яхшы. Тозлы кәбестәнең суы берничә сантиметрга өскә чыгып торырга тиеш. Мичкәдән кәбестә алган саен, аның өстен тигезләп, тыгызлап ябып, авыр әйбер куярга онытмагыз. Тозлы кәбестәне пыяла банкаларга бушатып, өстенә бер-ике бармак калынлыгы үсемлек мае салып сакларга да була. Алай итсәң, кәбестә җәй башына хәтле яхшы саклана.

• • •

Башлы кәбестәне кыш өчен сакларга базга куйганда, шиңмәгәннәрен, өшемәгәннәрен, киселмәгәнярылмаганнарын гына сайлап алырга кирәк. Бер урынга тезгәндә, кәбестәләрне бер-берсенә орынмаслык итеп куялар. Тезеп саклаганда, аның сабагын 2—3 см озынлыкта калдырсаң да ярый. Ләкин баз түшәменә асып саклаганда, аның сабагын бөтенләй кисмиләр. Кышын кәбестәне әледән-әле караштырып, саргайган яфракларын ташлап тору яхшы.

• • •

Кәбестәне парда пешергәндә аш серкәсе салыгыз. Ул кирәгеннән артык йомшармас. Чәчәкле кәбестәне сөттә парландырып пешерергә киңәш ителә.

• • •

Тозлы кәбестә ашын пешеп җиткәч кенә тозлагыз, югыйсә, артык тозлап җибәрүегез ихтимал.

• • •

Пешкән яшелчәләрне суында озак тотарга ярамый, алар тәмсезләнәләр, шуңа күрә пешеп җитү белән дуршлагка салып саркытырга кирәк. Бары тик чәчәкле кәбестәне генә пешкән суында бераз тотарга ярый.

• • •

Чәчәкле кәбестә арасына вак бөҗәкләр керүчән була. Шуңа күрә аны пешерер алдыннан 5—10 минут нык тозланган суда тотыгыз. Бөҗәкләр өскә калкыр һәм аларны суы белән бергә түгеп булыр.

СУГАН ҺӘМ САРЫМСАК

Борынгы заманнарда ук суган һәм сарымсакны ризык әзерләгәндә генә түгел, ә бәлки төрле чирләрдән дәвалану өчен дә кулланулары билгеле.

Башлы суган аеруча киң таралган: татлы, ярымтатлы һәм әче суган. Составында эфир майлары һәм гликозидлар (органик шикәрләр) булганлыктан, суган әче. Суган составында 4 проценттан 10 процентка кадәр шикәр, 0,65 процент минераль матдәләр бар. Ул витаминнарга бай.

Суганлы ризык тәмлерәк була, аны организм яхшырак үзләштерә.

Сарымсак та химик составы белән суганга якын тора. Аның составында да 10 процент чамасы шикәр һәм 0,5 процент минераль матдәләр бар. Әмма сарымсак суганга караганда витаминнарга ярлырак. Эфир майлары аңа үзенә бер төрле ис һәм тәм бирә. Ләкин алар ашказаны һәм эчәкләрнең өске лайлалы ярысына көчле тәэсир итә. Шуңа күрә ашказаны һәм эчәкләрдә ялкынсыну процессы булганда, бавыр һәм бөерләр авыртканда суган һәм сарымсак ашарга ярамый.

Бу яшелчә культураларының тагын шундый сыйфаты бар. Алар составындагы матдәләр-фитонцидлар — авырулар китереп чыгаручы күп төрле микробларның үрчүен һәм үсүен тоткарлый, аларны үтерә.

Сарымсактан аллилсат дигән дару ясыйлар. Ул, башка дарулар белән берләттән, гипертония һәм атеросклероз белән чирләүчеләрне дәвалау өчен кулланыла.

КОЛМАКТАН ЧҮПРӘ ЯСАУ

Яңа җыелган яки киптерелгән колмакны яхшылап юалар һәм, салкын су салып, биш-ун минут кайнаталар. Кул пешмәслек булып суынгач, юкә иләк яки марля аша сөзәләр. Йомшарган колмакны кул белән нычытып уып, суын сыгып алып бетергәннән соң чүбен ташлыйлар. Соңыннан колмак суы тагын бер тапкыр марля аша сөзелә һәм, арыш яки бодай оны өстәп, икеөч көнгә әчергә-күперергә куела. Шулай әчегән чүпрәне кирәк кадәр алып баш ясыйлар һәм шуңа камыр изәләр.

103 ЯШЬ!

Камәрия әби бүген дә иртәне бәйрәмчә каршылады. Кечкенә оныгы Резидә тегеп биргән күлмәген киде, Ташкенттагы кызы Нурия җибәргән кәшемир шәлне алып ябынды. Бәйрәмчә киенсә дә, теләге килененә бераз гына зарланып алу иде. Чөнки ике көн инде улы Заһитның Норлатта укытучы кызы Фәния белән үз авылларында укытучы улы Җәүдәт әбиләрен аптыратып бетерделәр:

— Әби, тиздән бик зур бәйрәм, бөтен балаларыңны кунакка чакырабыз, — диләр.

Илнең төрле ягына, тирә-күрше авылларга чакыру кәгазе язалар. Үзләренең шатлыклары эчләренә сыймый, йөгереп киләләр дә әбиләрен кочаклап алалар. Менә шул бәйрәм дигәннәре Камәрия әбинең таң йокыларын качырды да инде.

Шул вакыт, яңа савылган, иртәнге җылы сөт тотып, килене Рабига килеп керде. Янына килененең килеп утыруы карчыкка рәхәт булып китте. Ул бер-ике йотым сөт өчте дә үзенә тынгылык бирмәгән уйларын сөйли башлады:

— Бу балалар нишләргә уйлыйлар соң? Я, ярар, йөз яшьтән узыйм, ди. Ник инде аны бөтен дөньяга таратырга? Мин кем соң ул кадәре?

Рабига апа чүт кенә кычкырып көлеп җибәрмәде. Карчыкны үпкәләтүең мөмкин. «Бергә гомер иткән киленем дә көлә», — дип уйлар.

— И, әни, әни, — дип, кайнанасын кочаклап алды килене. Ана белән бала кебек күпме шулай утырганнардыр, вакыт сизелмичә үтте. Чөнки икесенә дә рәхәт иде. Алар шулай үткәннәрне искә алып, сөйләшеп утырырга яраталар. Бөтен хатирәләр яңара.

Камәрия әби шушы авылга кайчан килен булып төшкәнен хәтерләми дә инде. Карты Нургали белән биш бала үстерделәр. Сөеп-сөелешеп яшәр чакта, колхозлар төзелеп, тормышлар мул, еллар тынычлангач, ил өстенә кайгы килде. Сугыш Камәрия карчыкның берьюлы өч улын тартып алды. Төпчеген, 19 яшьлек Нәҗибен озатып калулары бигрәк авыр булган иде. Ике улыннан, соңгы хәбәр булып, кара кәгазь килде. Карты да уллары кайгысын күтәрә алмады. Тик Камәрия әби генә бирешергә теләмәде, язмыш белән, сугыш белән аяусыз көрәште. Ул, ике киленен — янындагы Рабигасын, күршедәге Мәүлиясен ияртеп, көне-төне колхоз эшенә йөрде.

Югыйсә, 70 яшькә җиткән карчыкны берәү дә эшкә кушмый иде. Улларының балаларын карап өйдә генә утырса да бик җиткән. Төннәрен мендәр читен тешләп елап үткәрсә дә, күз яшьләрен кешегә күрсәтми, эшкә йөри. Көне буе киленнәре белән уракта ярыша. Киленнәре узып китсәләр дә үпкәсе юк, ул шатлана гына: шулай булырга тиеш. Кайгы кешене аяктан ега, алда әле күпме эшлисе эш! Карчык, шуны тойган хәлдә, яшьләрне шаян сүзләре белән көлдереп алырга да, такмаклар әйтергә дә өлгерә. Авылдашларга рухи көч өсти.

...Улы Заһит та, кияүләре дә сугыштан исән-сау әйләнеп кайттылар. Сугышта да, тыныч тормышта да әбинең балалары йөзенә кызыллык китермәделәр. Тырышлар, уңганнар, эш дигәндә атлыгып торалар.

Ташкенттагы кызы белән улы тугызар, Шәмсиясе җиде бала үстерде. Сугышта үлгән Насыйхының да өч улы бик уңган егетләр. Оныклары арасында да кемнәр генә юк. Әбиләрен һич тә кызартырлык түгелләр. Әнә Заһиты белән Шәмсиясенең һәр баласы югары белемле. Алар бит барлыгы ике йортка уналты. Оныклар хәзер үзләре инде әби-бабай булыр алдында. Аларның да балалары югары уку йортларында укып йөриләр.

Бәйрәмгә бик күп кунаклар җыелды. Әбиебез чәчәкләр, бүләкләр уртасында күмелеп калды. Шул вакыт Октябрь районының «Татарстан» колхозында парторг булып эшләүче оныгы Сөләйман, уенын-чынын бергә кушып:

— Әби, синең иң яраткан кешең кем, кайсыбызны ныграк яратасың? — дип сорап куйды.

Әби уйга калды. Әйе, бар аның бик тә яраткан кешесе. Улы да, кызлары да түгел, ә килене — Рабигасы. Ничек яратмаска мөмкин соң аны. Алар бит инде 45 ел бергә яшиләр. Югыйсә, Рабига карчык үзе дә күптән инде кайнана. Шулай да әле ул кайнанасына һәр иртәдә җылы сөтне үзе эчертә.

Камәрия әбинең тормыш юлы кызыклы, гыйбрәтле һәм мактаулы. «Озын гомернең, сәламәтлекнең сере тормышыбызның яхшы, балаларымның тәүфыйклы булуында. Кунакка чакырсалар, балаларым я машина, я ат белән, я булмаса үзләре чана тартып алырга киләләр. Үз аякларым исән вакытта, берсенә дә утырасым килми әле. Балаларым турында яхшы хәбәр ишеткән саен яшәреп китәм», — ди 103 яшьлек Камәрия әби Вәлиева.

Фәния ХУҖИӘХМӘТОВА.
Октябрь районы, Кычытканлы авылы.

Баш редактор —
В. Ф. Ихсанова.

Редколлегия членнары:
Н. З. Закирова
Ә. Ш. Мусина
Л. М. Мәһдиева
И. Г. Сункишева
С. Г. Сөләйманова
К. А. Шәмсетдинова
Г. Ш. Шәрәфетдинов
(баш редактор урынбасары)
И. Г. Юзиев
З. Н. Якупова
Р. А. Җиһаншина

Художник
И. Әхмәдиев.

Техник редактор
Э. Әдиатуллина.

Общественно-политический и литературно-художественный журнал «Азат хатын» («ОСВОБОЖДЕННАЯ ЖЕНЩИНА») на татарском языке.

Производствога бирелде 20/IX-1977 ел.
Басарга кул куелды 20/X-1977 ел.
Тираж 362.000.
Заказ Б-345.
ПФ 07016.
Кәгазь форматы 60×90¹/₈.
Күләме 3 басма табак.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

ТЕЛЕФОННАР:

хатлар һәм авыл хуҗалыгы бүлекләре — 3-07-46;
промышленность, пропаганда, әдәбият һәм сәнгать бүлекләре — 3-07-42;
художник — 3-07-44;
фотокорреспондент — 3-07-67;
җаваплы секретарь — 3-57-69;
кабул итү бүлмәсе — 3-07-40;
баш редактор — 3-58-75.

БЕЗНЕҢ АДРЕС:
г. Казань — 420066,
ул. Декабристов, 2
редакция журнала
«АЗАТ ХАТЫН».








Монда күрсәтелгән киемнәр Казан фабрикаларында тегелә һәм республика кибетләренә озатыла.

Р. ЯКУПОВ фотолары.






Бәясе 20 тиен
Индекс 73002

ТЫШЛЫКНЫҢ БЕРЕНЧЕ БИТЕНДӘ: «Казанда бәйрәм»

Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ фотосы.

ТЫШЛЫКНЫҢ ДҮРТЕНЧЕ БИТЕНДӘ: «Кар эчендә... балан»

Н. М. КОЦАГА, В. Б. КАПКОВ фотосы.

